

«ВАМ КУДА?»
«ВТ» хәбәрчесенең хәрби комиссариатта күргәннәре

> 5

«Ә»НЕ КИМСЕТМӘ!
Шәһәрдә түгел, хәтта авылларда да балалар русча сөйләшә хәзер

> 15

ФИЛҮС КАҺИРОВ:
«Кайчак тормышның кайбер мизгелләре искә төшә дә, хәзер алай эшләмәс идем, дим»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 162 (29129) | Җомга | 3 ноябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4 604609 000131

«Татар-информ»

ТӘМЛЕ ЧОР

АВЫЛЛАРДА КАЗ ӨМӘЛӘРЕ БАШЛАНДЫ

Авылда һәр чорның – үз мәшәкате, үз бәрәкәте, үз муллыгы. Инде менә хәзерге вакытта каз өмәләре гөрли. Тик еллар узган саен, аларның да асылы үзгәрә. Авылларда каз-үрдәк чистартырга кеше таба алмыйча азапланалар, өмәгә йөри торган апаларыбыз өлкәнәя, яшьләр бу эштән читләшә. Тик шулай да һәр эштән чыгу җае бар. Анысы – һәркемнең үзенеке.

> 6

ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ КӨНЕ БЕЛӘН!



Халыклар бердәмлеге көне уңаеннан Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм МИҢНЕХАНОВ МӨРӘҖӘГАТЕ

Хөрмәтле татарстанлылар!
Кадерле ватандашлар!

Сезне Халыклар бердәмлеге көне уңаеннан чын йөрәктән тәбрик итәм!

Россия дәүләтенең күпгасырлык тарихы – халкыбызның гаять зур рухи куәткә ия булуын тагын бер кат раслый торган ачык дәлил.

Дүрт йөз ел элек туган җирне азат итү, эчке фетнәне сүндерү өчен күтәрелгән көрәштә барлык катлау һәм барлык халык вәкилләре бергәләшеп катнашты. Аннан соңгы гасырларда да илбасарлар нык ихтыярыбызны, үз-үзебезгә ышанычыбызны, ирекле тормышка, хаклыкка, бердәмлеккә омтылышыбызны какшата алмады.

Илгә моңарчы күрелмәгәнчә көчле басым ясалган хәзерге чорда Ватанның батыр уллары (алар арасында татарстанлылар да бик күп) Россиянең бәйсезлеген, иминлеген саклый. Алга таба да бу шулай булачак.

Татарстан Россиянең дәүләтчелеген, бердәмлеген ныгытуга лаеклы өлеш кертә, милләтләрнең һәм конфессияләрнең үзара татулыгы, килешеп гомер итүе үрнәге булып тора. Төрле халыклар вәкилләре хакимият органнары белән хезмәттәшлектә үзенчәлекле мәдәниятләрен, телләрен һәм күркәм йолаларын саклау һәм үстерү өчен тырыш хезмәт куя.

Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елында бай рухи хәзинәләребез дәверләр һәм буыннар бәйләнешендә, тарихи-мәдәни мирасыбызда аеруча калку чагылышка ия. Милләтенә карамастан, һәр кеше өчен яшәешнең нигезен Ватанга тугрылык, ярдәмләшү һәм гаделлеккә ирешү теләге тәшкил итә.

Хөрмәтле татарстанлылар, кыенлыкларга бирешмичә, барыбызга да хас булган тормышны ярату, бердәмлек һәм алдагы көннәргә өмет белән уртак Ватаныбыз – Россия Федерациясенең якты киләчәген тәэмин итүгә лаеклы өлеш кертербез дип ышанам.

Ихлас күңелдән сезгә саулык-сәламәтлек, тынычлык, игелек һәм бәхет телим!

КОНСТИТУЦИЯ БЕЗНЕ БЕРЛӘШТЕРДЕ

Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм МИҢНЕХАНОВның Татарстан Республикасы Конституциясе көне уңаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ

Хөрмәтле татарстанлылар!

Сезне Татарстан Республикасы Конституциясе көне уңаеннан ихлас йөрәктән тәбрик итәм!

Үзгәрешләр чорында кабул ителгән Конституция республиканың күпмилләтле халкы ихтыяры, аның тотрыклылыкны саклауга һәм социаль-икътисадый үсешне ныгытуга омтылуының ачык гәүдәләнеше булды.

Төп закон гражданнарның лаеклы тормышын тәэмин итүне үз алларына максат итеп куйган дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының нәтиҗәле эшчәнлеген оештырырга мөмкинлек бирде.

1992 елда кабул ителгән нормалар һәм нигезләмәләр татарстанлыларның традицион рухи-әхлакый хәзинәләргә һәм күркәм гаилә кыйммәтләренә тугрылыгын чагылдыра.

Конституция безне берләштерде, төрле халыклар телләренең һәм мәдәниятләренең үсешенә, рухи яңарышка бәрәкәтле этәргеч бирде, иҗтимагый, милли-мәдәни һәм дини берләшмәләргә үзләренең эшчәнлек юнәлешен билгеләргә ярдәм итте. Уртак тырышлык белән без милләтәр һәм диннәр арасында татулыкны тагын да ныгытуга ирештек, гадел тигезлекне саклап, изге урыннарны, архитектура истәлекләрен һәм тарихи ядкәрләрне торгыздык.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан быел кабул ителгән үзгәрешләр Төп Законның һәрчак заман рухына туры килүен раслый. Шул ук вакытта чыгышына, нинди расадан һәм милләттән булуына, торган урынына һәм башкаларга карамастан, кеше һәм гражданнар хокукларын һәм ирекләрен яклау өстенлеге үзгәрешсез кала.

Татарстанлыларның тырыш хезмәте, икътисад өлкәсендәге уңышлары нәтиҗәсендә республикабыз алга баруын дәвам итә, барлык социаль йөкләмәләр үтәлә.

Уңай үзгәрешләр ил җитәкчелегенең булышлыгыннан, дәүләтнең гражданнар турында кайгыртуыннан башка була алмас иде.

Ватанны саклаучылар илебезнең азатлыгы, бәйсезлеге өчен көрәшкән бүгенге көннәрдә без якташларыбыз белән горурланабыз һәм Җиңүгә ышанабыз!

Кадерле ватандашлар!

Сезне Татарстан Республикасының дәүләт бәйрәме уңаеннан тагын бер кат котлыйм һәм саулык-сәламәтлек, киләчәккә якты өметләр, хезмәт казанышлары, иминлек телим.

ЫШАНЫЧЛЫ КЫЙБЛА

tatarstan.ru

Санкт-Петербург берничә көнгә газ киләчәге турында сөйләшү, фикер алышу мәйданчыгына әйләнде. Биредә 12 нче халыкара газ форумы узды. Төньяк башкалада Татарстан җитәкчелеге дә, республика компанияләре дә булып кайтты.

Лидер төбәк

Төньяк башкалада узган форумда Татарстанга карата булган кызыксыну бер дә юкка түгел. Республика газмотор ягулыгы базары үсеше буенча ил төбәкләре рейтингы лидерлары рәтенә кергән. «Ышанычлы ориентир» номинациясендә җиңүче дип табылган Татарстан.

Лидер төбәк булуын саннар да дәлилли. Соңгы 10 елда Татарстанда кысылган табигый газ (метан) сату күләме – 16, АГНКС саны – 4 тапкыр, газ ягып эшли торган техника саны 26 тапкыр артты. 2023 ел азагына кимендә тагын 2 мең берәмлек транспортны табигый газга күчерү ниятләнә.

Форумда сөйләгәннәрдән

Аңлашыла инде: Россия – еллар белән сыналган партнер. Көнчыгышта да, Көнбатышта да моны яхшы аңлыйлар. Соңгылары исә хезмәттәшлекне үзләренә зыянлы файда ясап туктатты. Форумда да бу хакта берничә кат искәрттеләр. Хәзер дөньякүләм табигый газ базарының үзгәреш кичерүенә дә игътибар иттеләр.

Россия Көнбатыш илләреннән йөз чөермәде, әмма алар хезмәттәшлек итәргә әзер булмаса, теләнеп йөрүче булмаячак. Пленар утырышта Россиянең энергетика министры Николай Шульгинов әнә шундыйрак фикер җиткерде. «Газпром» идарәсе рәисе Алексей Миллерның да фикере шуңа охшаш булып чыкты. Компания чит ил «дуслар»ның китүен әллә ни тоймады да, сизмәде дә, дигән булды ул. Ә чикләүләрне исә узарбыз.

Татарстан «күчтәнәч»е

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов форум кысасында Алексей Миллер белән очрашты. Моннан тыш алар республика тәкъдим иткән стендны да карады.

«КАМАЗ» барлык тәгәрмәчләре дә тарта торган вахта автобусы тәкъдим итте. Аны «Газпром» заказы буенча Чаллыда җитештергәннәр. Әлеге техника дизель ягулыгы, табигый газ белән эшли.

Чаллы заводы «күчмә остаханә» дә тәкъдим итте. Бу машина нефть-газ тармагы өчен махсус эшләнгән, аның бурычы – төрле объектларда аппаратураны ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү. Моннан тыш, Рөстәм Миңнеханов белән Алексей Миллерга табигый газ белән эшләүче алты цилиндрлы двигательне дә күрсәттеләр. Аларны Чаллы заводының К5 тракторларына куярга җыеналар.

Рөстәм Миңнеханов «Газпром» идарәсе рәисе урынбасары Олег Аксютин белән дә сөйләшүләр үткәрде. Ике як Татарстанның берничә компаниясе белән хезмәттәшлек турында фикер алышты һәм килешүләр имзалады. Алар арасында республикадагы торак пунктларны газлаштыру, табигый газны мотор ягулыгы буларак куллану, газны янга калдыру өчен заманча ысуллар куллану мәсьәләләре бар.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ УКАЗЫ

2023 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Рәисе премияләрен бирү турында

Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Рәисе премиясен бирү комитеты тәкъдимнәрен караганнан соң **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Рәисе премияләрен түбәндәгеләргә бирергә:

1) Гафиятуллин Мөнир Минхәйдәр улына – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасары, «Спорткультавтотовары» акционер җәмгыяте генераль директорына;

2) Ермолаева Надежда Анатольевнага – «Гаиләнең рухи хәзинәләрен саклау үзәге» Татарстан төбәк иҗтимагый оешмасы җитәкчесенә;

3) Хөснуллина Таңсылу Солтан кызына – Татарстан Республикасының «Игелек планетасы» инвалид яшьләр һәм балалар төбәк иҗтимагый оешмасы рәисенә;

4) «Ватан уллары» физик культураны, спортны үстерүгә ярдәм итү һәм балаларга, яшьләргә патриотик тәрбия бирү төбәк үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасына;

5) Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен «Рубаха» автоном коммерциячел булмаган оешмасына;

6) «Казан шәһәренең мари милли-мәдәни мохтарияте» җирле иҗтимагый оешмасына;

7) Татарстан Республикасы «Казан әниләре» төбәк иҗтимагый хәйрия оешмасына;

8) «Россия ветераннар берлеге» Бөтенроссия ветераннар иҗтимагый оешмасының «Татарстан Республикасы ветераннар берлеге» республика ветераннар (инвалидлар) иҗтимагый оешмасына.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2023 ел, 28 октябрь, № 746

КЕРЕМ ҺӘМ ЧЫГЫМ

Дәүләт Советында

Кытлыксыз бюджет, машина йөртүчеләрнең хезмәт хакы һәм эшкә бармак аша караучы депутатларга шелтә. Алтынчы чакырылыш Татарстан Дәүләт Советының чираттагы утырышы әнә шулар белән истә калды.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашында узган кырык сигезенче утырышның дәвамын Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин алып барды. Дәвамы, чөнки утырыш моннан ике атна элек башланды. Көн тәртибендә сораулар күп булу сәбәпле, аны икегә бүләргә мәҗбүр булдылар.

Көн тәртибендә торган төп мәсьәлә – 2024 елга, 2025–2026 еллар план чорына бюджет турындагы закон проекты. Аны беренче укылышта тикшерделәр. Киләсе елда Татарстан бюджеты кытлыксыз булачак дип фаразлана. Керемнәр һәм чыгымнар 383,9 миллиард сум күләмендә көтелә. Гомумән алганда, 2024 елда тупланма бюджетның керем һәм чыгым өлеше 451,7 миллиард сум күләмендә көтелә.

Төп саннарны Татарстан финанс министры Радик Гайзатуллин китерде.

– Киләсе елда табышка салымның гомуми күләме 112,8 миллиард сум тәшкил итәчәк, – диде ул. – Физик затларның кеременә салым исә республика бюджетына – 96,4 миллиард сум, тупланма бюджетка 137,5 миллиард сум акча китерер дип фаразлана.

Алдагы өч елда барлык муниципаль берәмлекләрнең бюджетлары кытлыксыз булыр дип тә көтелә. Радик Гайзатуллин әйтүенчә, бюджетта беренче чираттагы һәм социаль әһәмияткә ия булган чыгымнарның күләме арта. «2024 елга республика бюджетының 84 проценты социаль характерда», – диде ул.

Аерым алганда, киләсе елда сәламәтлек саклау тармагына, мәҗбүри медицина иминияте чараларын да исәпкә алып, 108 миллиард сум акча тотарга җыеналар.

Парламентта республиканың төп финанс законын тикшерү бер сәгатьтән артык дәвам итте. Фәрит Мөхәммәтшин документны, утырышта яңгыраган төзәтмәләрне кертү шарты белән, беренче укылышта кабул итәргә тәкъдим итте. Депутатлар әлеге тәкъдимне хуплады.

2024 елга һәм 2025–2026 еллар план чорына Татарстан Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турындагы закон проектын тикшергәндә, депутатлар тагын бер мәсьәләгә игътибар итте. Соңгы арада республиканың төрле шәһәрләрендә ашыгыч ярдәм машинасы йөртүчеләрнең күпләп эштән китүе турында хәбәрләр таралды. «Чаллыда, мәсәлән, шуның аркасында 25 машинаның 17се генә юлга чыга», – диде депутатлар.

Фонд җитәкчесе Алсу Мифтахова әйтүенчә, машина йөртүчеләр, хезмәт хакы түбән булганлыктан, эштән китә. Акчаны арттырырга җыеналар. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин мәсьәләне кичекмәстән хәл итәргә кушты. Аның әйтүенчә, табибларның авырлар янына вакытында барып җитә алмавына юл куярга ярамый.

Парламент җитәкчесе эшкә салкын караган депутатларга да шелтә белдерде.

– Утырыш башланганда тавыш бирүдә катнашучы депутатлар саны 79 булса, хәзер 74кә генә калды. Сез тавыш бирмичә утырасызмы әллә? Игътибарлырак булырга киңәш итәм. Безгә кыенлыклар тудырмагыз. Дәүләт Думасында утырышларга йөрмәгән ике депутатның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктаттылар әнә. Бездә дә бу мәсьәлә килеп туарлык булмасын. Озак утырасы килми, аңлашыла. Әмма безнең эшебез шул, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Утырышта Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе эшчәнлеге турында да сөйләштеләр.

– Социаль челтәрләр тормышыбызга бик нык үтеп керде. Кирәкле мәгълүмат белән янәшә кирәкмәгәне дә бар. Моннан файдаланып калырга теләүчеләр дә күп, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Дагыстандагы хәлләрне генә искә төшерегез. Халыкны, бигрәк тә яшьләрне мондый мәгълүматтан сакларга кирәк.

Парламент җитәкчесе мондый ресурсларда «утыручы»лардан бигрәк, әлеге төр каналларны уйлап табучыларның юлын ябарга киңәш итте. «Моның ысуллары бармы?» – дип кызыксынды ул идарә җитәкчесе Юрий Никитиннан. Тик җавап әллә ни сөендермәде. «Технологияләр гел яңарып тора, шуңа күрә безгә еш кына арттан куарга туры килә», – диде ул.

Утырыш ахырында депутатлар моннан ике атна элек арабыздан киткән Татарстанның халык шагыйре, җәмәгать эшлеклесе Разил Вәлиевне бер минут тынлык белән искә алды.

Эльвира ВӘЛИЕВА

ГАЗЗӘГӘ ЯРДӘМ

Республикада Газзә секторы халкына гуманитар ярдәм җыю үзәге оештырыла. Бу эш Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов күрсәтмәсе нигезендә алып барыла.
Татар мөселманнары Диния нәзарәте белән Мисырның «Кызыл ярымай» оешмасы зыян күрүчеләргә кирәкле азык-төлек һәм кирәк-ярак исемлеген төзегән. Халыктан азык-төлек, шәхси гигиена әйберләре, көнкүреш кирәк-яраклары кабул итәләр. Тулы исемлек **ярдям.рф** сайтында урнаштырылган.
Ярдәмне 3 ноябрьдән кабул итә башлаячаклар. Артык зур булмаган кирәк-яракларны «Ярдәм янәшә» хәрәкәтенең офисына (**Патрис Лумумба урамы, 4 йорт, 112 кабинет**) китерергә мөмкин. Зур әйберләрне **Мәҗит Гафури урамы, 46 йорт** адресы буенча кабул итәләр.
Гуманитар ярдәмне иртәнге сәгать тугыздан кичке бишкә кадәр китерергә мөмкин.
Тулырак мәгълүматны «Ярдәм янәшә»нең рәсми сайтына кереп яки **8(843)2731672, 88003500216 номерлары** аша «кайнар элемтә» телефонына шалтыратып белешергә мөмкин.
Моннан тыш, гуманитар ярдәмне Татарстан Диния нәзарәтенең «Зәкят» фондында да кабул итәләр. **Телефоннары: 8(843) 225 33 22.**

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының элекке хакимияте башлыгы **МАКАРОВ Валерий Владимирович**ның гомере вакытсыз өзелү сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Бурлык

«Авыл бетмәсә, бурлык бетми», – дип шаярта торганнар иде без яшьрәк вакытта. Дөресе дә шулай иде бугай. Фермадан саламын-печәнен ташый торган идек. Сөт алып кайта идек. Вакыты белән оны да эләгә. Мин кечкенәдән фермада үскән малай булгач, бу һөнәрләрнең барысына да хәреф таный башлаганчы ук өйрәндем. «Колхозныкын алу бурлык түгел ул, бары тик тереклегенә генә тимәскә кирәк», – дип тә әйтәләр иде.

Чынлап та кош-корт яки мал-туарга тию бик зур гаеп санала, тотылган кешегә җәзасы да каты, авылдашларның мөнәсәбәте дә кырыс иде. Тавык яки сарык бәрәне урлау – бик начар гамәл. Әрерәге турында әйтеп тә торасы юк инде. Ә вак-төягә бурлыкка да чутланмый...

Моның тагын бер ягы бар иде әле. Ул сөтне чиләкләп алып кайтмый бит берәү дә, ярты литр чамасы кайтып торса җитә. Сенаж-силосы да шулай, бер капчык алып кайтсаң, абзарыңдагы бөтен малың тук була. Бер сыердан артык асрарга рөхсәт юк иде безнең якта. Шуңа мал азыгы артык күп кирәкми иде бугай. Көндәлеге кайтып торса – Аллаһка шөкер. Артыгын алсаң, артык эш кенә була – чыгарып түгәргә кирәк. Шуңа күрә аз-азлап кына көн саен урлашу намуслылыкның бер чагылышы кебек тоела иде. Коммунистик бурлык.

Аннан соң үзгәртеп корулар башланды. Бөтен җирдә бөтен нәрсәне үзгәртергә тырыша башладылар. Ил үзгәрде. Власть үзгәрде. Кешенең асылы гына үзгәрмәде.

Кибет киштәләре Горбачев бабайның пеләше кебек ялтырап калгач, шәһәрдә дә, авылда да бурлык хуҗа булып, күкрәк киереп йөри башлады. Авыл җирендә эчкечеләр артты. Моңарчы, рәхәт тормышка күчеп, бәхетлерәк яши башларбыз, бары тик армый-талмый эшләргә генә кирәк дип, ихлас күңелдән тир түккән авыл халкы ул чорда бераз аптырап калды. Кулыннан эше төште. Эш коралын рюмкага алыштырган тәркемнәр барлыкка килде. Тормышның төбенә төшеп, юешләнеп беткән менә шундый адәмнәр авыл кешесенең җайлы яткан бөтен нәрсәсен дә эләктерергә күнегеп киттеләр. Кәрәксәнәк тә, балта да, чүпрәк-чапрак та булырга мөмкин ул. Бер очта урлыйлар да икенче урамга илтеп саталар, шул акчага өченче урамда самогон сатып алалар. Аяк астында уралып йөргән кош-кортыңны да эләктерергә мөмкиннәр, кабымлык та кирәк бит. Алкашлар гына урлашса, бер хәл әле. Тормыш дулкынында көймәләрен коры тотарга күнеккән халык та читтә калмады.

Соңрак илнең байлыгын бүлешү ыгы-зыгысы башланды. Монда инде җинаять тәхетенә «талау» дигән нәрсә менде. Урам уртасында көпә-көндез талап китәргә дә мөмкиннәр, йортыңа килеп таларга да күп сорамыйлар. Бугазыңа – пычак яки маңгаеңа пистолет терәсәләр, үзең дә илтеп бирергә мөмкинсең... Бурлык чорын без сагындык хәтта. Мондый күренешләр янында бурлык җинаять булып тоелмады, ул бишектә яткан бер гөнаһсыз сабый кебек күренде.

Әнә шул сабыйның үсеп җитүен без үз күзләребез белән күреп тордык. Вакыт-вакыт башыннан сыйпап, иркәләп тә алдык, шуклыкларын күреп елмайдык, уңышларын күреп сөендек. Бишектәге шул баланың үсеп, тәпи киткәнен дә сокланып күзәттек, теле ачылганда һәр сүзенә шатланып кул чабып тордык. Үзебезчә сөйләшергә дә өйрәтмәкче булдык. Ә ул матур да, батыр да егеткә әверелде, булдыклы да иде – адым саен эшен киңрәк җәелдерә барды. Ә көннәрнең берендә безнең тормышыбызга тулысынча ул хуҗа икәнен аңладык.

Үзебез карап үстергән бала ич ул...

Әйтеп кенә бактым

Сыеныр урын

Риман
ГЫЙЛЕМХАНОВ

«Васильево» шифаханәсенә икенче килүем. Миңа монда нарат урманы һавасы, кешеләре ошый. Тик быел ял итәргә килүчеләр ничектер башкарак, сәеррәк тоелды: балалы ялгыз хатыннар, таякка таянганнар күбрәк иде. Телләрендә дә бераз ятрак акцент сизелгәндәй булды (русларның көньяк сөйләме иде бугай ул), күп сүзләрне йомшак әйтәләр.

Күрше бүлмәдән бер абзыйны коляскага утыртып алып чыгалар да, ике култыгыннан алып, аякка басарга булышалар. Аннан таякка таяна да теге якка биш адым, бу якка биш адым дигәндәй атлап йөрергә өйрәнә башлый бу. Түзмәдем: «Сез кайдан?» – дип сорадым. Мине баштанаяк күздән кичерде дә, бераз шикләнеп, күзләремә карады. Әйтергәме-юкмы, дип икеләнә кебек иде ул. Теләр-теләмәс кенә: «Издалека», – дип куйды. Артык төпченергә уңайсызландым, шулай да: «А что с ногой?» – дидем. Икебез дә таяклы булгангамы, сүзләр ялганып китте тагын үзе.

Мариупольдән килгәннәр икән болар. «Болар» дигәнем – үзе, хатыны һәм яшүсмер бер кыз. Аны да нигәдер җитәкләп йөриләр. Хуҗа кеше үзенең исем-фамилиясен тулысынча әйтмәде: «Федорович мин», – дип кенә куйды. Күрәсең, бөтенләй ачылып китәргә шикләнә иде. 2022 елда Мариупольне Украина милләтчеләреннән азат итү өчен махсус операция барганда, Федорович яшәгән йортка снаряд төшкән. Снаряд кыйпылчыклары тиеп, аңын югалткан, хатыны җитәкләп йөрткән кыз – оныклары икән, ул да снаряд төшеп имгәнгән, хатыны өйдә булмаган.

Мариуполь вакыйгаларын телеэкраннар аша туктаусыз күрсәттеләр, интернет сайтлары да төрле мәгълүматлардан ташып торды. Ә Федорович – шул вакыйгаларның тере шаһиты һәм үзеннән берни дә өстәп сөйләми иде. Мин моны кистереп әйтә алам, чөнки Мариуполь хәлләрен төрле, хәтта башка идеологиягә хезмәт иткән мәгълүмат чаралары аша да шактый өйрәндем. Ә бу юлы Федорович сөйләгәннәрдән чыгып кына язам. «Көнчыгыш Украинада тормышыбыз бик әйбәт, мул иде. Тик Көнбатыш безгә тынгылык бирмәде, андагы халык Польша, Австрия белән иснәшеп яшәде», – ди ул.

Аның әйткәннәренә куәт итеп, бер-ике сүз өстим әле. Заманында Украинаның көнбатышындагы шактый җирләр Польша һәм Австриянеке була, шуңа күрә әлеге ике ил, элекке җирләрен кире кайтару өчен, теләсә нинди адымга барачак. Аларның фашистик режимны яклавы да күпмедер дәрәҗәдә җир өчен талашка бәйледер, дип уйлыйбыз.

Федорович әйтүенчә, махсус хәрби операция башлангач, Киев режимы яклылар Мариуполь халкын шәһәрне ташлап чыкмаска өндәп йөргәннәр. Янәсе, берниндн сугыш булмас, булса да, шәһәр читендә бер-ике көн чәкәләшеп кенә алырлар. «Ә үзләре бөтен торак йортларны, ясле, мәктәпләрне ныгытмаларга әйләндереп бетерделәр», – ди Федорович.

Без сөйләшеп торганда, яныбызга бер әби килеп туктады. Луганскидан икән. Үземчә провокацион сорау биргән булам: «Сезне кем утка тотты?» – дим. «Зеленский, конечно», – ди әби. Нәрсәдер әйтеп сүгенмәкче иде, уңайсызланып туктап калды.

«Васильево» шифаханәсе үзенә 140 тирәсе качакны сыендырган булган. Хәзер алар утыз бишләп кенә. Кайберләре үзләренә пар табып гаилә корган, эшкә урнашкан, кайберләре туган якларына кайтып киткән.

«Ә сез нишләмәкче буласыз, китәсезме, Татарстанда каласызмы?» – дип сорыйм Федоровичтан. Туган-торган нигезгә бик кайтасылары килә аларның. Тик менә оялары туздырылган. Федорович: «Путин нам поможет», – ди. Алар җимерелгән шәһәрнең торгызылачагына ышанып яшиләр, ә үзләренә сыену урыны биргән Татарстанга бик рәхмәтлеләр. «Народ у вас очень хороший, очень гостеприимный», – диләр. Яхшы сүзегезгә рәхмәт инде. Без – шатлыгын да, кайгысын да уртаклашып яшәргә өйрәнгән халык шул.

БӘХЕТ ЭЗЛӘГӘНДӘ

Рәшит
ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

vk.com

«Ватсап» төркемнәренең берсендә бераү: «Бәхет ул – тән сәламәтлеге», – дип язып куйды. Мондый раслау белән килешеп үк бетәсе килмәде. «Бай һәм таза-сау кешеләрнең үз-үзләренә кул салуларын ничек аңлатасыз?» – дип эндәштем. Җавап кыска булды: «Алар – рәхәтлеккә чыдый алмаучылар». Укучылар дөрес аңласын: автор һич кенә дә тән сәламәтлегенә тискәре бәя бирергә җыенмый. Каты авыру, бигрәк тә дәвалауга бирешми торган чир булса, чынлап та, күпчелек очракта кешене үзен бәхетсез итеп тоярга мәҗбүр итә. Әмма бар кешене дә түгел.

Сентябрьнең кояшлы һәм җылы көннәрендә бу юлларның авторы тирә-як авыллар буйлап сәяхәт итәргә гадәтләнде. Утыз-утыз биш километрлы радиуста педаль әйләндерде. Авылларның берсеннән узып барганда, юл кырыенда җирдән аз гына калкып торган ярты гәүдә арттан нидер кычкырып калгач, кире борылып килде. Тездән югарырак киселгән аяклар, бот сөягенә киертеп куелган зур аяк киеме. Кеше ял итәргә чыккан. Протез да юк, коляска да, аларның юклыгына кайгырмый да шикелле. Аңа аралашырга кеше кирәк, бары шул гына. Сөйләшеп киттек. Мин инде, билгеле, аякларын кайда югалтуын сорадым. Үз гаебе аркасында фаҗигагә тарыган икән, ике аягын да кисәргә туры килгән. Фаҗигасен ул, елмаеп, бер дә зарланмыйча сөйләп бирде. Кеше – гарип, әмма үзен бәхетсез тоймый. Кыска вакытлы әңгәмәдән шул аңлашыла иде.

Дүрт саны тулы килеш, байлыкка һәм дәрәҗәгә ирешкән кешеләрнең «рәхәткә чыдый алмыйча» үз-үзләренә кул салулары бәхет турындагы уйларны үзгәртергә мәҗбүр итә. Соңгы атналарда гына «Лукойл»ның тагын бер топ-менеджеры серле үлем белән үлеп китте. Аның турында, туктый алмыйча, кара янып әчкән дигән сүзләр күренгәләде. Бу компаниянең бишенчеме-алтынчымы менеджеры шулай гомерен кисәк төгәлләде инде. Америкадагы эре финанс холдингларының берсенең башкаручы директоры күптән түгел генә офис тәрәзәсеннән түбәнгә сикерде... Тапталган юлдан китү өчен гафу итегез, мин сөйләмәсәм дә, сәламәтлек, байлык, дан-дәрәҗә, абруйның бәхет чыганагы була алмавы турында мисалларны күп беләсез. Киресенчә, күпчелек очракларда алар бәхетсезлек ачкычына әвереләләр, монысы да күпләргә мәгълүм. Әмма кешеләр, бәхетле булабыз дип, инстинктив рәвештә барыбер шуларга омтыла.

Нәфес теләкләренә ияру кешене бәхетле итә алмый. Килешәм: фәкыйрьлек тә бәхет түгел. Ул да адәм баласын сагышка һәм хәсрәткә сала. Шуңа күрә кешеләр өстендә йөк булмаслык дәрәҗәдә ихтыяҗ итәргә – тырышырга туры килә. Ибн әл-Каим нәрсә ди әле? «Сагыш-кайгы һәм мәшәкать баскан кешеләрнең күпчелеге – ялкаулар, аларның ни шатлыгы, ни бәхете юк, – ди. – Актив һәм эшләрендә тырышлык күрсәтүче кешеләрдә исә барысы да киресенчә».

Физик хәрәкәт һәм эшнең җанга да, тәнгә дә ләззәт бирүе – факт. Кул кушырып, берни дә эшләми тик яту – депрессиягә илтә торган нәрсә, бу да – билгеле әйбер. «Рәхәткә чыдый алмау» дигәндә нигездә без шуны күз алдында тотабыз. Дөнья малын һәм ризыгын максатка әверелдереп, шуңа омтылу да нәкъ шундый ук нәтиҗәгә китерә: кеше омтылганына ирешә, әмма үзен бәхетле тоя алмый. Яшәү өчен кирәкле матди нәрсәләрне максатка әйләндерү бәхетле итә алмый да, чөнки алар – яшәүнең чарасы гына. Ашау өчен яши башласа, кеше ризыкның түмен тоймый башлый.

Югарыда сөйләгәннәрне мисал белән дәлиллик әле. Атаклы Һиндстан мультимиллиардеры, 291 миллиард долларлык байлык иясе Ратан Татка сүз бирик: «Мин чын бәхетнең ни икәнен аңлаганчы бәхетнең дүрт стадиясен үттем. Беренче адымым байлык һәм ресурслар туплау булды. Ләкин мин алардан теләгән бәхетемне ала алмадым. Икенче этап – затлы әйберләр җыю этабы килеп җитте. Ләкин аңладым: нәтиҗә – вакытлыча гына, кыйммәтле әйберләрнең ялтыравы озакка бармый. Аннан зур проектлар этабы башланды. Минем кулда Һиндстан һәм Африка нефть запасының 95 проценты иде. Мин Һиндстандагы һәм Африкадагы иң зур корыч кою заводы хуҗасы булдым. Бу да миңа үзем хыялланган бәхетне бирмәде, – дип сөйли ул. – Дүртенче этап дустымның гарип балаларга инвалид коляскасы сатып алуымны үтенгәч килеп җитте. Ике йөзләп шундый бала бар иде. Шунда ук коляскалар сатып алдым. Әмма дустым аларны үзем илтеп тапшыруны таләп итте. Әзерләндем дә киттем. Анда үз кулларым белән балаларга инвалид коляскалары бүләк иттем. Ул балаларның йөзендәге гаҗәеп бәхет нурларын күрдем. Аларның ничек үз коляскаларына утырып хәрәкәтләнүен һәм уйнауларын күрдем. Үземне эчтән бик бәхетле тойдым. Китәргә җыенгач, балаларның берсе аягымнан эләктереп алды. Мин аягымны акрын гына ычкындырмакчы булдым, әмма бала йөземә карады да аякларымны тагын да ныграк кысты. Иелеп, баладан: «Сиңа тагын берәр нәрсә кирәкме әллә?» – дип сорадым. Баланың җавабы мине тетрәндереп кенә калмады, тормышка карашымны үзгәртте: «Мин синең йөзеңне Аллаһ каршында күрешкәч тану һәм тагын бер тапкыр рәхмәт әйтү өчен хәтерләп калырга телим», – диде».

Хикәянең асылын аңлагансыздыр инде: адәм баласын бу дөньяда без уңыш дип санаган нәрсәләрнең берсе дә бәхетле итә алмый. Алар вакытлыча ләззәт бирергә мөмкин, әмма ләззәт тиз үтә. Чын бәхет исә максаты мәңгелеккә юнәлдерелгән игелек кылганда гына килә. Иман әһелләре шуңа күрә пәйгамбәрнең (саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең): «Бу дөнья мөселманнар өчен – зиндан, кяферләр өчен – җәннәт», – дигән сүзләрен истә тоталар. Ул сүзләрне Мисыр казые Хафиз ибн Хәҗәр менә ничек шәрехли. Көннәрдән бер көнне Хафиз ибн Хәҗәр затлы киемнәрдән базар буйлап атлый икән. Сәләмә киемле бер яһүди аның качырының йөгәненнән тоткан һәм: «Әй, шәйхуль ислам! Син сезнең пәйгамбәрегез (саллаллаһу галәйһи вә сәлләм): «Бу дөнья тормышы мөэминнәр өчен – зиндан, ә кяферләр өчен – җәннәт», – дип әйткән, дисең. Бу кадәр зиннәттә булып, син ничек төрмәдә дә, мине син күргән хәлдә булып, мин ничек җәннәттә?» – дип сораган. Казый: «Минем хәзерге хәлем Аллаһ ахирәткә инанганнарга вәгъдә иткән җәннәт белән чагыштырганда төрмә кебек, ә синең хәзерге хәлең сине ахирәттә көткән газаплар белән чагыштырганда җәннәткә тиң», – дигән. Дөнья малы һәм сәламәтлек ахирәт уңышына илтерлек гамәлләр белән бизәлгәндә генә кешене бәхетле итә ала дигән нәтиҗә белән тәгәллик язманы.

«АНДА СЕЗНЕ КӨТӘЛӘР(МЕ)?»

«ВТ» ХӘБӘРЧЕСЕ ПИТРӘЧ РАЙОНЫ ХӘРБИ КОМИССАРИАТЫНДА БУЛДЫ

Вакытында кирәк! Татарстанда контракт буенча хәрби хезмәткә алу дәвам итә. Җаваплы эш хәрби комиссариатларга гына түгел, башка оешмаларга да йөкләнгән. Казанда кәгазь эшен бер көндә ерып чыгарга була. Ә районнарда контракт төзергә җыенган кешегә мөнәсәбәт ничек? Эш ничек оештырылган? Шул сорауларга җавап эзләп, «ВТ» хәбәрчесе башкалага янәшә урнашкан Питрәчкә юл тотты.

«Татар-информ»

«Вам куда?» Питрәч районындагы хәрби комиссариат бинасының ишеген ачып кергәч, беренче сорау әнә шул булды. «Пока сюда, а потом поглядим». Контракт буенча хәрби хезмәт узу турында сорашырга килгәнне әйткәч, уң якка борылырга куштылар. Мондый эштә кай якка баруың да мөһим бит. Яшь һәм мөлаем гына туташ каршы алды. Дөресен әйткәндә, бу дәрәҗәдәге җитди вазыйфаны ир-егетләргә ышанып тапшыралардыр дип уйлаган идем. Юк икән, биредә Ватан сакчысы булырга теләгән кешенең сорауларына гүзәл зат җавап бирә булып чыкты.

Гаиләсеннән аерылып, ерак юлга чыгарга җыенган кешенең сораулары аз булмый бит инде. Әйтик, акча турында кызыксыну – гадәти нәрсә. Билгеле булганча, контракт төзегән өчен Россия Оборона министрлыгы биргән акчадан тыш, төбәкләр, район һәм шәһәрләр, предприятиеләрдән саллы гына күләмдә өстәмә суммалар түләнә.

Казанда, мәсәлән, шәһәр – 200 мең, ә китәсе кеше эшләгән оешма тагын 100 мең сум акча түли. Ә Питрәчтә ничек? Кызганыч, бу сорау җавапсыз калды. «Белмим», – диде туташ. Кайчан алып китәчәкләр? Бу хакта да кистереп әйтүче булмады.

Белешмә тутыру өчен хәрби билет, никахлашу, балалар туу турындагы таныклыклар алып килергә кирәк. Документларны туплап, Казанга җибәрәләр. Аннары хәбәр көтәсең.

Документ эшенә тотынганчы, табибка күренә торсаң да була. «Анда сезне көтәләр, баш табибка кереп әйтегез. Тикшеренүне бер көндә узып чыгарсыз. Аннары табиблар чыгарган нәтиҗә белән безгә килерсез. Җомгадан калмагыз инде», – дип озатып калды хәрби комиссариаттагы туташ. Киттек Питрәч районының үзәк хастаханәсенә.

Баш табибның кабул итү бүлмәсендә аның урынбасары янына барырга куштылар. Тик анда әләгү җиңел түгел. Ишек төбендә чират. Ничек инде, миңа комиссариаттан куштылар дип, алардан алга узмак кирәк?! Олы яшьтәге ике апаның чиратны бернәрсәгә дә алмаштырмаячаклары күренеп тора: «Мы тут с девяти»! Баласын күтәреп килгән яшь кенә ханымның үз хәле хәл. Кыскасы, биш ай элек күршесенең үгезен суйганда, мал типкәч, аягы сынган авыл абзые белән безгә чират җиткәндә сәгать телләре 12не суккан иде. Әбәт вакыты! Юк, дөрес уйламыйсыз, кабул итте баш табиб урынбасары һәм әле җиңелчә генә ачуланып та куйды: «Чиратсыз керергә иде! Контрактчыларга бездә – яшел коридор! Махсус шәфкать туташы билгеләдек. Табибларга сезне ул йөртәчәк! Әмма төштән соң инде».

Төштән соң медицина картасы тутыргач, табибка күренә башладык. Хәрби комиссариатта, контракт буенча белешергә дип, аларга көненә 1–2 кеше килгәнне әйткәннәр иде, ә без өчәү булдык.

51 яшьлек ир-егетнең исемен сорауны кирәк дип тапмадым. «Төрле эшләр башкардым. Соңгы вакытта эшмәкәрлек белән дә шөгыльләндем. Менә хәзер хәрби булырга исәп. Бик күп дусларым махсус хәрби операция зонасында. Мин дә шунда булырга тиеш дигән карарга килдем. Өйдәгеләр ни әйтәме? Балалар зур инде, аларның үз тормышы, үз мәшәкате...» – диде ул артык ачылып китмичә.

Өченчебез – 40 яшьлек ханым. Казандагы хастаханәләрнең берсендә эшли. Контракт төзеп, санитар булырга исәбе. «Ялга чыккач, утырып уйладым да менә шундый җаваплы адымга барырга булдым. Акчада түгел хикмәт. Бертуган энем дә махсус хәрби операция зонасында. Улыма әйттем – каршы килмәдe. Кызым әлегә белми...»

Питрәч табибларының эшенә беренче карашка тел-теш тидерерлек түгел. Ике сәгать дигәндә кирәкле белгечләргә күренеп тә чыктык. Сүз уңаеннан, күптән мондый җентекле тикшеренү узган юк иде. Дөрес, сәламәтлек турында белешмәне бер көндә генә әзерләп бетерә алмыйлар. Чөнки кайбер анализларны Казанга юлларга кирәк. «Сезнең хәрби хезмәткә яраклы булуыгыз турындагы белешмә иртәгә төштән соң әзер булыр», – дип озатып калдылар хастаханәдә. Нәтиҗәне ничек алдан чамалый алганнарын сорап тормадым.

Тикшеренергә сишәмбе бардык, чәршәмбе нәтиҗәләр әле билгеле түгел иде. Шалтыратып сорагач, анализлар хәтта Казанга да китмәгән булып чыкты. Нәтиҗәләрнең әзер булганын пәнҗешәмбе кичке якта гына белә алдым. Димәк, бер көн эчендә документлар әзерләнә дип уйлау – ялгыш фикер.

Үз аягы белән килеп кергән «контрактник»ны район хәрби комиссариатында күтәреп йөриләрдер дисәм, ялгышканмын: миңа карата артык кызыксыну тоймадым. Дөрес, икенче көнне бер ир-ат шалтыратты. Үзен Питрәч хәрби комиссариатында хәрби хезмәткә сайлап алу өчен җаваплы кеше дип таныштырды. «Кичә сез бездә булгансыз, мин Казанда идем. Килегез, барысын да сөйләрбез, аңлатырбыз», – диде. Минем белән аралашкан, сорауларыма җавап бирә алмаган туташ кем булды – анысын аңлый алмадым. Тик ул көнне контракт буенча хәрби хезмәткә китәргә теләп мөрәҗәгать итүчеләр тагын булса, аларның да юллары уңмагандыр дип чамалыйм...

БЕЛЕП ЭШЛИЛӘР

Татарстанда контракт буенча хәрби хезмәткә китәргә теләүчеләр арткан. Хәзер алар арасында яшьләр күбрәк икән. Казанда контракт буенча хәрби хезмәткә сайлап алу пункты башлыгы урынбасары Рөстәм Сафиуллин әйтүенчә, теләк белдерүчеләр арасында чит ил кешеләре дә бар.

Моңа кадәр контракт төзергә дип мөрәҗәгать итүчеләр көненә 30–40 кеше булса, хәзер көнаралаш 100дән артык ир-егетне хәрби хезмәткә җибәрәләр.

– Беренчедән, җәйге яллар тәмамланды. Икенчедән, контракт төзүчеләргә өстәмә акча түләнә. Халык боларның барысын да белеп тора. Хәзер егетләр барысын да белеп эшли. Әйтик, дуслары хезмәт иткән частьларны сайлыйлар. Бергә булганда җиңелрәк бит. Моңа кадәр шикләнгән кешеләр дә барысын да аңлый башлады. Җәмгыятьтә дә тынычрак кабул итәләр, – ди Рөстәм Сафиуллин. – Элегрәк безгә яше 30–40тан артканнар килә иде. Хәзер исә күптән түгел армиядән кайткан яки хәрби хезмәттә бөтенләй булмаган яшь егетләр мөрәҗәгать итә. Контракт төзүчеләр арасында чит ил кешеләре, әйтик, Кубадан, Якын Көнчыгыш илләреннән килүчеләр дә бар. Аларны Россия гражданлыгы алу һәм зур күләмдә хезмәт хакы кызыксындыра.

Контракт төзүчеләр арасында хатын-кызлар да бар. Алар медицина хезмәткәре, санитар, радиотелефонист булып китә. Әле күптән түгел генә Себердән килгән 20 яшьлек ике кызны хәрби хезмәткә юллаганнар.

КИЛЕГЕЗ! Сайлап алу пунктына яки яшәү урыны буенча хәрби комиссариатка

ШАЛТЫРАТЫГЫЗ! 117 Контракт буенча хәрби хезмәт узу мәсьәләләре буенча «кайнар линия»

БЕЛЕШЕГЕЗ! HEROES-TATARSTAN.RU

ТӘМЛЕ ЧОР

АВЫЛЛАРДА КАЗ ӨМӘЛӘРЕ БАШЛАНДЫ

«ВТ» архивыннан

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Ашаучысы бар, чистартучы юк

Мөслим районының Әмәкәй авылында яшәүче Ралинә Бәширова хуҗалыгында каз өмәләре 30 октябрьдә башланып киткән. Фермерлар алдында зур бурыч тора: декабрьгә кадәр 6 мең баш казны чистартып, эшен бетерәсе бар. Тик әлегә эшләр бик сүлпән бара, ди хуҗабикә.

– Кызганыч, ике кулларына бер эш булмаган кешеләрне дә өмәгә чакырып китереп булмый. Әлегә үзебезнең авылдан һәм күрше-тирә авыллардан дүрт апа килеп йөри. Үзган ел да шулар ярдәме белән башкарып чыккан идек. Аларның берсе 45 яшьләр тирәсендә, калганнары өлкәнрәк. Бер каз чистарткан өчен 200 сум акча бирәбез. Авылларына барып алабыз, үз машиналары белән килгән очракта, бензин хакын түлибез, – ди фермер.

Эшләр өчен барлык шартлар тудырылган югыйсә. Суы агып тора, эш тәртибе – элеккечә.

– Безнең исәпләүләр буенча, декабрьгә кадәр эшне бетерер өчен, көненә 100 каз чистартырга кирәк. Әлегә көненә 30–40ны гына эшкәртәбез. Кар яугач, кошның шырпысы бетә, ул вакытта җиңелрәк чистартыла. Бер кеше 20 каз йолкый ала. Безнең якларда каз асраучылар күп. Метрәй авылында, мәсәлән, каз чистарту цехы бар. Анда автомат эшли. Бер башында кош-кортны чалсалар, икенчесендә пешеклиләр, өченчесендә чистарталар, дүртенчесендә эч-башларын эшкәртәләр. Балавыз белән эшләү шулай ук вакытны янга калдырырга ярдәм итә, – ди ул.

Шулай да, Ралинә әйтүенчә, кул хезмәтенә җитми инде. Машина чистарткан кош-кортның төс-кыяфәте бозылып китәргә мөмкин икән.

– Кем ничек булдыра, шулай җаен эзли инде. Кешеләргә илтеп биреп чистарттыручылар да бар. Тик анда контроль бетә. Намуссыз эшләүчеләр дә бар. Кошны никадәр күп асрасаң да, сату авыр түгел. Сатып алучылар елдан-ел арта, тик чистартучылар гына азая. Киләчәктә апаларыбыз килми башласа, үзебез дә машина белән эшкәртмичә хәлебез юк, – ди Ралинә.

Саба районы Явлаштау авылында исә өмәләр нәкъ элеккечә, туган-тумача, күрше-күлән ярдәме белән уза.

– Әни, кош-корт җене кагылганга, ел саен каз яки үрдәк үстерә. Быел инде алмыбыз дигәннәр иде. Абый өйләнеп, гаиләбез ишәйгәч, алдык, – ди Рәфидә Галимҗанова. – Гадәттә 10–15 баш алабыз да җәй буе үстерәбез. Быел 11 үрдәк асрадык. Өмәләргә гадәттә туган апалар, әби, әнинең апалары һәм хәзер инде кодагыйлар да килә. Быел барлыгы 7 кеше чистарттык. Бер елны да каз чистартырга кеше таба алмыйча азапланганыбыз юк. Өмәчеләрне әни октябрь азагында яки ноябрьдә җыя башлый. Үзган елларда алар өмәгә чиратлашып йөри иде: башта безгә җыелышып килсәләр, аннары шул составта туганнарга баралар. Гадәттә каз һәм үрдәк өмәләре бездә туганнар белән җыелы сөйләшүгә корылган була. Анда бөтен авыл яңалыклары сөйләнә, кызыгы да, тәме дә шунда инде.

Төп булышчылар – балалар

Буа районының Ташкичү авылында элек-электән казларны күпләп асрыйлар. Мәшәкате күп булып, табышы бер дә күренмәсә, шулкадәр каз асрап азапланмаслар да иде. Димәк, файдасы бар. Казның түшкәсен дә, эч-башларын да, йонын да бик теләп алалар икән. Каклап, ыслап та саталар.

– Каз булгач, өмәсе ничек булмасын инде? Бездә меңәр башка кадәр үстерүчеләр бар, шуңа күрә авылларда өмәләр гөрли башлады. Эчтәлеге үзгәрсә дә, барыбер җыелышып чистарту бар бит инде. Ялгыз гына башкара торган эшләр түгел. Бездә халык каз чистартырга күрше Чувашия хатыннарын чакыра. Алар өч бригада булып йөри. Бер каз чистарткан өчен 180 сум бирәбез. Гадәттә ун хатын-кыз килә дә 100 казны эшкәртеп китә. Менә быел мин эшне озакка сузмыйча, бер көндә бетерергә исәпләп торам. Туганнар, апалар да кайта. Бергәләп эшләячәкбез. Мин бервакытта да яллап кына эшләтү яклы түгел. Бары быз бергә мәш киләбез, чөнки эшнең тизрәк бетүе кирәк. Кош асрауның авырлыгы юк аның, эшкәртүе күпкә мәшәкатьлерәк, – ди Салих Әхмәдуллин.

Ә менә Алабуга районының Морты авылында яшәүче Хуҗиннар, 500 баш казны, тәвәккәлләп, үзләре генә чистартырга керешкән. Гөлнара белән Илнарның төп ярдәмчеләре – хуҗабикәнең әнисе һәм балалары.

– 9 һәм 12 яшьлек балалар минем белән беррәттән чистарта. Башта бер атна куркәләрне урнаштырдык, менә хәзер казларга тотындык, – диде Гөлнара Хуҗина. – Балалар каникулда чакта күбесен чистартып бетерсәк, декабрьгә кадәр эшне тәмамлыйсы иде. Үзган елларны әнием килә алмады, шуңа күрә күрше авылдан апаларны алып килә идек. Бер каз чистарткан өчен 500 сум түләдек. Инде заказлар да алабыз. Яңа чистарткан казларны ыслый башладык, ә каклар өчен бераз көтәргә кирәк.

Зөһрә САДЫЙКОВА

БӘЯЛӘРЕ	
Түшкәсе (бер килограммы)	600–650 сум
Эч-башлары (баш, йөрәк, бавыр, бүтәкә, тәпиләр)	150–400 сум
Эретелмәгән каз мае (килограммы)	250 сум
Эретелгән май (бер литры)	300 сум
Ысланган һәм какланган каз (бер килограммы)	1200 сум

Каз чистартучы: «70 мең сумнан артык акча эшлибез»

Чувашиянең Батыр районындагы Кызыл Чишмә авылы кызлары Татарстанның Буа, Апас, Кайбыч, Арча районнарына каз йолкырга йөри. Без аларның бригадирлары Гөлназ САФИУЛЛИНА белән сөйләштек.

:: Гөлназ апа, өмәләргә күптәннән йөрисезме?

– 10–15 ел элек йөри башлаган идем. Бүген бригадада 5–6 хатын-кыз эшли. Барыбызның да төп эшебез бар. Монысын өстәмә эш буларак алабыз. Акча эшләү җае булгач, өмә вакытларын барыбыз да зур түземсезлек белән көтеп алабыз. Сезон 1,5 айга сузыла. Бу вакыт эчендә, гадәттә, 40–45 кешегә ярдәм итәбез. Көненә 60–100 каз чистартабыз. Быел өмәләр 20 октябрьдән соң башланды. Ноябрьдә бер генә буш көнебез дә юк. Бер каз чистарткан өчен 180 сум акча бирәләр, көненә уртача алганда 2000 сум эшләп була. Көн саен эшләгән очракта, сезонга 70 мең сум тирәсе керем кертү мөмкинлеге бар.

:: Бер казны тулысынча чистарту өчен бер кешегә күпме вакыт кирәк?

– Бер сәгатькә якын. Гадәттә, бер өмәдә бер кеше ун каз йолкый. Килешү шулай. Нәфесләнеп, кеше өлешенә керү килешми. Өмәгә барасы кешеләр саны да бер атна алдан билгеле була.

:: Каз чистартуның иң авыры нәрсә?

– Каз йолкуның бөтен эше авыр, ләкин яратып башкарган хезмәт җиңеләя. Бик ансат булса, авыл халкы үзе генә дә өмә ясап эшләп бетерер иде. Тик авыллар картая, хуҗалар кеше таба алмый азаплана. Үзебезнең бригада кызлары да 50 яшьтә инде. Кеше күбрәк кирәк булганда, пенсиядәге бер-ике апаны дәшәбез. Яшьрәкләр инде килми. Сезон ахырына үзебезнең дә кул бармаклары, бил сызлап авырта башлый. Каз чистартыр өчен җитезлек тә, пөхтәлек тә, көч тә кирәк. Йонын йолку авыррак, эчен эшкәртү җиңелрәк. Шулай да кумәкләшеп, сөйләшеп, җырлашып эшләгәндә күңелле.

:: Эшне җиңеләйтү серләре бармы?

– Эшкә тизрәк, җәһәтрәк эшли торган кеше «Бисмиллаһ» әйтеп тотына. Без казларның йоннарын үтүкләп чистартабыз. Элек хуҗалар су белән пешекләп эшләтәләр иде, хәзер алар да безгә иярде. Шырпылы чаклары, бала йоннары чыкканнары да була. Ул салкынга, җылыга да карамый. Ә менә яхшы ашаткан казлар эре, матур була. Гадәттә кукуруз, бодай ашатканнарныкы таза, ап-ак, авырлыклары да зур була. Хуҗалар якты йөз белән каршы алалар, тәмле ашаталар, эшне оештыралар. Шулай да бөтен кешегә теләп бармыйбыз. Авыр холыклы кешеләрдә эш бармый. Әле бер, әле икенче мәшәкать килеп чыгып тора андыйларда. Йә казлары артык пешеп китә, йә үтүкләре эшләми.

ЮККА ТҮГЕЛ

ТӨП СТАВКАНЫҢ АРТУЫ НӘРСӘГӘ КИТЕРӘЧӘК?

Мәгълүм булганча, Үзәк банк төп ставканы 13 проценттан 15 процентка кадәр күтәрде. Мондый кискен үзгәреш җиленең икътисад, көнкүреш ягына исмичә калуы мөмкин дә түгел, билгеле. «ВТ» кабат «Хәзерге икътисадый вазгыятьтә нәрсә эшләргә?» дигән сорауга җавап эзләде.

Без әле кая барабыз? Татарстан Иҗтимагый палатасының финанс һәм икътисад мәсьәләләре буенча белгече **Фәнис ХӨСӘЕНОВ** белән шул хакта сөйләштек.

:: Фәнис Сәярович, төп ставка ник үзгәрә һәм ул инфляциягә ничек бәйле?

– Үзәк банкның төп максаты – бәяләрне йөгәнләү. Аларга инфляциянең 4 проценттан да артмавы мөһим. Моның өчен нишләргә? Төп ставканы үзгәртергә. Нәрсә ул төп ставка? Гади итеп әйтсәк, төп ставка – банкларның Үзәк банктан бурычка акча алып торырга мөмкинлек бирә торган процент ставкасы. Бу очракта – 15 процент. Фаразларга караганда, инфляция күрсәткече 7 процентка җитәргә мөмкин. Шуңа күрә Үзәк банк, хәлне үзгәртү өчен, ставканы күтәрә дә инде. Төп ставка югарырак булган саен, инфляция күрсәткече азрак була. Хәзерге чынбарлыкта ставканы 15 процентка кадәр күтәрү инфляциянең акрынаюына китерде. Шуңа күрә Үзәк банкның бу ысулы нәтиҗәсен бирде дип санарга була.

Инфляцияне түбәндәгечә акрынайту күздә тотыла: төп ставка арта → кредитлар кыйммәтләнә → югары ставкалы кертемнәр тәкъдим ителә → халык чыгымнарын киметә һәм акча тупларга омтыла → инфляция акрыная.

:: Төп ставканың артуы нәрсәгә китерәчәк?

Бизнес. Кредит ставкалары арта. Базар икътисады шартларында яшәвебезне онытмыйк. Мондый вазгыятьтә бизнес кредитсыз яши алмый. Күпчелек компанияләр кредит алырга мәҗбүр.

Халык. Яңа кредитлар кыйммәтрәк булачак. Моны аңларга кирәк. Ә элек алган кредитлар өчен борчыласы түгел. Закон белән яклаган алар. Үзгәрешләр булган очракта, физик затларның гамәлдәге кредитлары ставкасын үзгәртмәскә дигән канун бар. Аңлашыла инде: халык кредитка яши. Хәзерге үзгәрешләр кредиттан файдалану мөмкинлеген киметәчәк. Физик затлар импорт товарларын, машиналарны азрак ала башлаячак, мәсәлән.

Икътисад. Кредит кыйммәтрәк булган саен, бәяләр дә үсә дигән сүз. Димәк, икътисад үсеше акрынаячак.

Банк. Үзәк банкның төп ставканы күтәрүе депозитлар буенча шартларны яхшыртачак, кертемнәрнең проценталры үсәчәк. Кыска вакытлы кертемнәр отышлы, ике-өч еллык срокка салынган кертемнәр яхшы табыш китерәчәк.

Әйтүемчә, Үзәк банкның хәзерге максаты – сум белән долларның үзара мөнәсәбәте дә түгел, ә нәкъ менә инфляция. Хәзерге шартларда ставканы арттыру сумның гайре тотрыклануына китермәде. Әйтик, ставканы күтәргәнче сум курсы 98–100 булса, хәзер 92–94 тирәсе. Бу әллә ни зур үзгәреш түгел. Һәрхәлдә, башкачарак булыр дип көтелгән иде.

:: Кредит, ипотека алу авыраячак, димәк?

– Әйе, бу шулай. Ташламалы ипотека тарифын файдаланган очракта, ставка үзгәрми анысы. Әмма беренчел кертем күләмен арттырып маташалар. Гади итеп әйтсәк, Үзәк банк халыкның кредит алу сәләтен мөмкин кадәр киметергә тырыша. Иң элек бу торак базарына кагылачак. Сүз дә юк, кулланучы кредитлары да күтәреп булмастай йөккә әйләнә.

ru.freepik.com

:: Акчаны банкка салган очракта нәрсәне истә тотарга?

– Кертем процентлары хәзер бик яхшы. Кешеләр акчаны сарыф итмәсен, банкка китерсен өчен эшләнә бу. Иминият суммасын истә тотарга киңәш итәм. Банкка ул-бу була калса, 1 млн 400 мең сум акча гына кире кайтасын онытмагыз. Күбрәк акчагыз була торып, кертем итеп сакларга теләсәгез, төрле банкларга бүлеп саклагыз.

:: Товарларга бәя дә арта бара...

– Бәяләр төшәр дип өметләнергә кирәкми. Максат товарларга бәя киметү түгел бит. Максат – бәя артуы тизләген киметү. Төп ставканы 15 процентка күтәрү, билгеле, товар бәясе төшүгә китермәячәк. Бәя үзгәреше еш кына сезонга бәйле. Әйтик, яшелчәләр, җиләк-җимешләр. Алар сезонга бәйле рәвештә сизелерлек менә йә төшә. Ә, әйтик, импорт товарлары сезонга бәйле түгел бит. Алар доллар белән сум курсына һәм әлеге товарларга ихтыяҗның ни дәрәҗәдә булуына бәйле.

:: Традицион сорауларның берсе. Андый-мондый үзгәреш була калса, халык күпләп товар сатып алу ягын кайгырта башлый. Товар җыя башларгамы инде?

– Юк, кирәк түгел. Бигрәк тә тиз бозыла торган продукцияне. Азык-төлеккә бәяләрне дәүләт контрольдә тота. Төп товарларга бәяне йөгәнләп торырга тырышалар.

:: Акчаны ничек тотарга?

– Алтын кагыйдә: финанс ягыннан белемле булырга һәм финанс «мендәр»ен тупларга. Финанс «мендәр»ендә 6 айга җитәрлек акча булса яхшы. Күңел ачу, ресторан-кафеларда утыру өчен кирәк сумма түгел бу. «Мендәр»дә даими ихтыяҗларыгызны капларлык, сезгә кирәкле минимум акча күләме булырга тиеш.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Югары ставка	Түбән ставка
Сум тотрыклана	Сум йомшара
Икътисадта акча кыйммәтләнә	Акча арзаная
Кредит ставкасы арта	Кредит буенча ставкалар кими
Кертем һәм тупланма счет буенча ставкалар арта	Кертем һәм тупланма счет буенча ставкалар кими
Халыкның сатып алу сәләте кими	Халыкның сатып алу сәләте тотрыклана
Инфляция акрыная	Инфляция яңадан тизләнә башларга мөмкин
Ил эчендә икътисадый үсеш темплары акрыная	Җитештерү үсеше тизләнә

ХАЛЫК АВАЗЫ

10 ноябрьдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Чулпан ГАРИФУЛЛИНА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

Кая мөрәҗәгать итим?

Мин – 26 ел стажлы педагог. Россия Социаль фонды пенсиянең иминият өлешен билгели. Шуннан соң «Волга-капитал» дәүләтнеке булмаган пенсия фондына тупланма өлеш сорап мөрәҗәгать иттем. Документларны Мәскәүгә җибәрделәр, Мәскәүдән тупланма өлешне 5 елдан соң гына түләргә дигән күрсәтмә килгән. Мин хәзер кая мөрәҗәгать итим?

Исеме күрсәтелмәгән

Булат Закиров, «ВТ» юристы:

– Кызганыч, сорау бирүче тулы мәгълүмат күрсәтмәгән, аңа ничә яшь булуы да билгесез. Тупланма пенсия ир-атларга – 60, хатын-кызларга 55 яшьтән бирелә. Мәскәүдән килгән күрсәтмә белән җентеклебрәк танышырга тәкъдим итәм. Яисә дәүләтнеке булмаган пенсия фондыннан тупланма пенсияне ни өчен түләмәүләре турында тулы җавап соратырга. Әгәр дә хокукларыгыз бозылган дип шикләнсәгез, прокуратурага мөрәҗәгать итәргә була.

Редакциядән. Хөрмәтле укучылар! Хокукка бәйле сораулар биргән очракта, тулы мәгълүматны күрсәтергә дә онытмасагыз иде. Сезнең сорауларга төпле җавап алуда алар бик ярдәм итә.

«ТНВ»дан киткәнме?

«ТНВ» каналында яңалыкларны Илгиз исемле Акташ егете алып бара иде. Соңгы арада югалды. Ялда гынадыр, дип уйлаган идек. Тик озакка китте. Илгиз кайда икән?

Яшел Үзәннән РӘМЗИЯ апагыз

Редакциядән. Хөрмәтле укучыбыз! Илгиз Шәкүров үзенең социаль челтәрендә каналдан китүе турында хәбәр иткән иде. Билгеле булганча, ул бу урында 4 ел эшләгән. «Тормышымдагы тагын бер якты этапны тәгәллим. Тәҗрибә, мөмкинлекләр – барысы өчен дә рәхмәт. «Син телевизордагы егет түгелме соң?» – дип килеп тотып-тотып караган, матур теләкләр әйтеп торган, мине якын иткән тамашачыга рәхмәт!» – дигән Илгиз.

Хатта хата юкмы?

Салым хаты килде. Тик анда ни өчендер Тула банкы реквизитлары күрсәтелгән. Ялгыш җибәрелгәнме әллә дисәм, танышларыма да салым инспекциясеннән шундый ук хат килгән. Без түләгән салым башка шәһәргә китәме?

Расих ҖӘЛӘЛ.
Казан

Гөлфия Каюмова, Салым федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсенең салым түләүчеләр белән эшләү бүлеге башлыгы:

– 2023 елның 1 гыйнварыннан Салым федераль хезмәте бердәм салым исәбенә (ЕНС) күчү сәбәпле, барлык салым түләүләре Тула шәһәре казначылыгы аша башкарыла. Барлык түләүләр шунда эшкәртелеп, үзебезнең төбәк бюджетларына керәчәк. Ул чит шәһәрләрдә калмый. Салым инспекцияләре җибәргән түләү хәбәрләрендә барлык реквизитлар дөрес күрсәтелгән.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

6 ноябрь | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

21.15 «Вести - Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «ЯЗМЫШЛАРДАН УЗМЫШ ЮК ИКӘН» 16+
10.00, 17.30 «Алмаш» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30 «Халкым минем...» 12+
12.00, 22.10 «Департамент» 16+
13.00 «Семь дней» 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
14.50 «Халкыбыз мирасы» 6+
18.00 «Кто мы татары?» 12+
18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Заман көзгесе» 6+
23.00 «ИСЧЕЗНУВШАЯ» 16+
00.00 «Соотечественники» 16+
00.25 «В стране дружбы...» 12+
00.50 «Путь» 16+
01.05 «Семь дней+» 16+
01.30 «Татар халык җырлары» 0+
02.00 «Манзара» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Халкыбыз мирасы – Народное наследие» 6+
08.00, 00.15 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
13.05 «Тарихлы да син, яшь тә син, Татарстан» 6+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30 «Заман көзгесе» 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.10, 22.10, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
19.35 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
21.55 «Туган авылым» 12+
00.40 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
01.05 «Манзара» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

05.35 «БЕРЕГИСЬ АВТОМОБИЛЯ» 12+
06.00, 10.00, 12.00 Новости
07.25 «НЕБЕСНЫЙ ТИХОХОД» 0+
09.00 «Парад 1941 года на Красной площади» 12+
10.15 «Играем свадьбу!» 12+
11.05 Жизнь других» 12+
12.15 «Шоу Вована и Лексуса» 16+
12.55 «Империя: Елизавета Петровна» 12+
15.00 «НАЧАЛЬНИК РАЗВЕДКИ» 16+
17.05 «Баня, водка, гармонь, Голливуд» 16+
18.00 Вечерние новости
19.00 «Перепой звезду» 12+
21.00 «Время»
23.00 «ТРОЦКИЙ» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Летописи конца времен» 16+
00.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
01.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
03.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
03.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+

РОССИЯ 1

04.45 «ЭТО МОЯ СОБАКА» 12+
06.30 «СОВСЕМ ЧУЖИЕ» 12+
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести
11.40. «Призрак Великой Финляндии. Преступление без наказания» 16+
12.35 «ВСЕМ ПО 50» 12+
17.50 «Песни от всей души» 12+
21.15 Вести. Местное время
21.30 «ЕКАТЕРИНА. ФАВОРИТЫ» 16+
22.30 «СЕРЕБРЯНЫЕ КОНЬКИ» 16+
01.05 «ДЕМОН РЕВОЛЮЦИИ» 16+
03.00 «КАНДАГАР»16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Спортивный век» 12+
06.30 «Всё о главном» 12+
07.00, 09.30, 13.05 Новости
07.05, 13.30, 00.30 Все на Матч!
09.35 «Метеор на ринге» 0+
09.55 Бокс. Чемпионат России. Женщины
13.10 Специальный репортаж 12+
13.55 Хоккей. Международный турнир «Лига Ставок Кубок Будущего». Россия (U20) – Россия (U18)
16.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Спартак» (Москва) – СКА (Санкт-Петербург)
19.15 Футбол. МИР РПЛ. «Сочи» – «Динамо» (Москва)
21.30 После футбола
22.30 БЕТСИТИ. Вечер профессионального бокса
01.30 «Магия большого спорта» 12+
02.00 Футбол. Чемпионат Германии. «Вольфсбург» – «Вердер» 6+
04.00 Новости 0+
04.05 Баскетбол. Единая лига ВТБ. МБА (Москва) – «Астана» (Казахстан) 6+

НТВ

04.50 «ТЕЛОХРАНИТЕЛЬ» 16+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.20 «БЕЛОЕ СОЛНЦЕ ПУСТЫНИ» 0+
10.20. «1983» 16+
12.30 «ОТСТАВНИК. ЗАЩИТА ДЕДОВА» 16+
15.35 «ОТСТАВНИК. БЛИЖНИЙ БОЙ» 16+
19.30 «ОЧЕНЬ СИНЯЯ БОРОДА» 6+
22.50 «Услышь меня» 12+
00.45 «ТЭФИ-KIDS-2023» 0+
02.20 «ЖЕСТОКАЯ ЛЮБОВЬ» 18+
04.05 «СВЕТ И ТЕНЬ МАЯКА» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30, 00.55 «СКАРЛЕТТ» 16+
10.45 «ВСЁ К ЛУЧШЕМУ» 16+
14.45 «ВСЁ К ЛУЧШЕМУ 2» 16+
19.00 «КАМЕННОЕ СЕРДЦЕ» 16+
23.00 «ЛЮБОВЬ КАК МОТИВ» 16+

ЗВЕЗДА

05.35 «СВИДЕТЕЛЬСТВО О БЕДНОСТИ» 12+
06.50 «КОМАНДИР КОРАБЛЯ» 12+
09.00 «Новости недели» 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.40 «Скрытые угрозы» 16+
11.30 «Код доступа» 12+
12.20 «Легенды армии» 12+
13.10 «Время вперед» 16+
18.00 Главное 16+
19.40 «Легенды советского сыска» 16+
23.00 «Фетисов» 12+
23.50 «Люди Донбасса» 16+
00.10 «ДЕМИДОВЫ» 12+
02.50 «Неизвестная война. Великая Отечественная» 16+
03.55 «ОПЕРАЦИЯ «ГОРГОНА» 16+

7 ноябрь | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10, 02.00 «Манзара» 16+
07.00, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00 «Алмаш» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 16+
11.15, 00.25 «Если хочешь быть здоровым» 16+
11.30, 15.45 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «Департамент» 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.15 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Барыс» – «Ак барс» 6+
19.00, 00.40 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Соотечественники» 16+
23.00 «ИСЧЕЗНУВШАЯ» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
01.05 «Башваткыч» 12+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Кәмит Җавит» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 18.20, 23.10. 04.20 «Җырлыйк әле!» 12+
09.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Халкым минем» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ТРОЦКИЙ» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 «Ефим Славский. Титан атомного века» 12+
01.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
01.50 ПОДКАСТ.ЛАБ «Все хотят летать» 16+
02.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «Кот Шрёдингера» 16+
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+
03.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «ЕКАТЕРИНА. ФАВОРИТЫ» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.05 «ДЕМОН РЕВОЛЮЦИИ» 16+
02.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Спортивный век» 12+
06.30 «Наши иностранцы» 12+
07.00, 09.30, 13.05, 15.25, 18.10 Новости
07.05, 16.00, 19.45, 01.00 Все на Матч!
09.35, 13.10 Специальный репортаж 12+
09.55 Бокс. Чемпионат России. Женщины
13.30 «Есть тема!»
14.55 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 6+
15.30 «География спорта. Петрозаводск» 12+
17.00 Футбол. МИР РПЛ. Обзор тура 6+
18.15 Брейкинг. Международный турнир «Лига Ставок Russian Open Breaking Championships» 0+
20.30 Футбол. Лига чемпионов. «Боруссия» (Дортмунд, Германия) – «Ньюкасл» (Англия)
22.45 Футбол. Лига чемпионов. «Милан» (Италия) – ПСЖ (Франция)
02.00 Футбол. Лига чемпионов. «Манчестер Сити» (Англия) – «Янг Бойз» (Швейцария) 6+
04.00 Новости 0+
04.05 Велоспорт. Трек. Лига чемпионов 0+

НТВ

04.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» 16+
22.15 «БАЛАБОЛ» 16+
01.55 «БЕЛОЕ СОЛНЦЕ ПУСТЫНИ» 0+
03.20 «СВЕТ И ТЕНЬ МАЯКА» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.25 «Давай разведёмся!» 16+
08.25 «Тест на отцовство» 16+
10.40, 23.05 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.15 «Порча» 16+
12.50, 01.10 «Знахарка» 16+
13.20, 01.35 «Верну любимого» 16+
13.55, 02.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.30 «Твой Domашний доктор» 16+
14.45 «СКОЛЬКО ЖИВЁТ ЛЮБОВЬ» 16+
19.00 «ЗЕРКАЛО ДЛЯ ОБОРОТНЯ» 16+
02.30 «СКОЛЬКО ЖИВЁТ ЛЮБОВЬ» 16+
05.35 «6 кадров» 16+
05.45 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00 «Освобождение» 16+
11.35, 13.25, 15.05 «ОПЕРАЦИЯ «НЕМАН» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «Битва за Россию» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Улика из прошлого» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ИХ ЗНАЛИ ТОЛЬКО В ЛИЦО» 12+
01.15 «СВИДЕТЕЛЬСТВО О БЕДНОСТИ» 12+
02.20 «ПО ДАННЫМ УГОЛОВНОГО РОЗЫСКА...» 12+
03.35 «Неизвестная война. Великая Отечественная» 16+
05.15 «Перелом. Хроника Победы» 16+

РФ КОРАЛЛЫ КӨЧЛӘРЕНДӘ КОНТРАКТ БУЕНЧА ХЕЗМӘТ ИТҮ

ТАШЛАМАЛАР һәм ГАРАНТИЯЛӘР HEROES.TATAR 117

- РОССИЯ ОБОРОНА МИНИСТРЛЫГЫ ХИСАБЫНА ТУПЛАНМА-ИПОТЕКА СИСТЕМАСЫ АША ТИЗ АРАДА ТОРАК САТЫП АЛУ МӨМКИНЛЕГЕ
- ХЕЗМӘТ УРЫНЫННАН ТОРАК ЯКИ ТОРАКНЫ НАЙМГА АЛЫП ТОРГАН ӨЧЕН КОМПЕНСАЦИЯ
- ХӘРБИ-МЕДИЦИНА УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ БУШЛАЙ ТИКШЕРЕНУ, ДӘВАЛАНУ ҺӘМ РЕАБИЛИТАЦИЯ УЗУ
- ФЕДЕРАЛЬ БЮДЖЕТ ХИСАБЫНА ГОМЕРНЕ ҺӘМ СӘЛАМӘТЛЕКНЕ ИМИНИЯТЛӘШТЕРУ
- 20 ЕЛ ХЕЗМӘТ ИТКӘННӘН СОҢ ТАШЛАМАЛЫ ПЕНСИЯ АЛУ ХОКУКЛАРЫ
- ХӘРБИ ХӘРӘКӘТЛӘР ВЕТЕРАНЫ СТАТУСЫ ҺӘМ ТИЕШЛЕ ТАШЛАМАЛАР
- КРЕДИТ ҺӘМ САЛЫМ КАНИКУЛЛАРЫ
- БАЛАЛАРНЫ ВУЗДА БУШЛАЙ УКЫТУ
- БАЛАЛАРГА ҖӘЙГЕ САВЫКТЫРУ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА БУШЛАЙ ЯЛ
- КОНТРАКТ БУЕНЧА ХЕЗМӘТ ИТҮЧЕ ХӘРБИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРГӘ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ СУБЪЕКТЛАРЫННАН БЕРДӘМ ӨСТӘМӘ ТҮЛӘҮЛӘР, ТАШЛАМАЛАР ҺӘМ ГАРАНТИЯЛӘР

АВЫРТЫР ДА БЕТӘР, ДИМӘ

pixabay.com

Җир шарында яшәүчеләрнең 90 проценты елга бер тапкыр булса да баш авыртудан зарлана. Рәсми саннар шул хакта сөйли. Яшерен-батырын түгел, күпләр баш авыртуга җитди карамый, аны үзлегеннән бетә торган күренеш итеп кенә кабул итә. Әмма белгечләр андыйларга сак булырга куша. Баш авырту җитди чир билгесе булырга да мөмкин, дип кисәтә алар.

Баш авыртуның төрләре, аны җиңү юллары турында табиб-невролог, реабилитолог, медицина фәннәре кандидаты Диләрә ШАҺИЕВА сөйләде.

●Баш авырту бик күп төрле авыруларның билгесе булырга мөмкин. Шуңа күрә аңа үтәр әле дип кенә кул селтәргә ярамый. Организмда кан әйләнеше бозылса, кеше еш кына баш авыртудан интегә. Ул инсультның беренче билгесе дә булырга мөмкин. Андый чакта кешене, гадәттә, пульс тибеше сыман баш авыртуы борчый. Аневризма (кан тамырлары стенасы бүртү) кебек куркыныч чир дә баш авырту рәвешендә уза. Иң куркынычы шул: баш авырту яман шеш билгесе дә була ала. Шеш булса, ул баш миенә басым ясый. Кан басымы уйнаган кешеләр баш авыртудан аеруча еш интегә. Андый чакта кан тамырлары киеренке халәтдә эшләргә мәҗбүр. Кан басымы бер төшү, бер менү аркасында баш миендә хәтергә тискәре йогынты ясаучы урыннар пәйда була. Шул рәвешле кешенең хәтере дә начарланырга мөмкин. Сүз уңаеннан, холестерин арту сәбәпле, кан әйләнеше бозылган кешеләрнең дә хәтере начарлана. Шуңа күрә вакытында табибка күренеп торырга кирәк.

●Төрле авыру вакытында баш төрлечә авырта. Мисал өчен коронавирус вакытында баш төрле җирдән борчый. Берәүләрнең – чигәдән, икенчеләрнең – баш артыннан. Пульс типкән сыман авырту да борчырга мөмкин. Аннары коронавирус вакытында баш бик нык һәм озак авырта. Чагыштыру өчен: гадәти баш авырту дәрәҗәсе 3–4 балл белән бәяләнсә, ковид вакытында ул 7–8 баллга җитә. Коронавирус белән авыручылар арасында баш авырту аркасында икенче якка борылып ята алмыйча тилмерүчеләр дә булды. Мигрень вакытында баш бер яктан гына авырта. Моннан тыш кеше төрле ис, тавыш, яктылыкка да сизгер була башлый.

●Әйткәнемчә, баш авырту җитди чирләр турында да кисәтә ала. Шуңа күрә даруга үрелергә ашыкмагыз. Дару баш авыртуны вакытлыча гына басачак. Шуңа күрә баш авырту гел борчыса, табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Баш пульс рәвешендә авыртса, аеруча игътибарлы булу сорала.

●Соңгы арада баш авырту балалар арасында еш күзәтелә башлады. Хәтта яңа туган нарасыйлар арасында да очрый ул. Андый чакта сабый начар йоклый, башын артка җибәрә, тынгысызлана. Нарасыйның баш авыртуы туганда имгәнүгә дә бәйле булырга мөмкин. Шуңа күрә алда телгә алынган үзгәрешләрнең берсе генә күзгә ташланса да, баланы педиатрга, остеопатка күрсәтергә кирәк.

●Баш авырту нәрсә ашавыбызга да бәйле. Шуңа күрә аннан интеккән кешеләргә шоколад, каһвә, чикләвек, кызыл шәраб кулланудан тыелырга киңәш ителә. Алар баш авырту ихтималын бермә-бер арттыра.

ДҮРТ КИҢӘШ

✓Баш авыртмасын өчен, вакытында йокларга ятып, вакытында торырга кирәк.

✓Көн дәвамында утырып эшләүчеләргә дөрес итеп утырырга кирәк. Арка – туры, компьютер мониторы күз биеклегендә булырга тиеш. Аяклар 90 градуска бөгелгән, куллар өстәлдә булса яхшы.

✓Баш авыртмасын, дисәң, аякны аяк өстенә куеп утырырга да киңәш ителми. Бер сәгать утыргач, гәүдәне яздырып, йөреп килергә дә онытмагыз.

✓Бүлмәне даими рәвештә җилләтеп торуның да файдасы зур.

БАШ АВЫРТУНЫ БАСА ТОРГАН РИЗЫКЛАР

➤Баш күп очракта организмга су җитмәү аркасында авырта. Шуңа күрә көн дәвамында чиста су эчүне гадәткә кертегез.

➤Магний кан тамырларын йомшарта, шул рәвешле баш авыртуны да кисәтә. Шуңа күрә составында магний күп булган (көнбагыш, кабак төше, диңгез кәбестәсе, авокадо һ.б.) ризыкларга өстенлек бирегез.

➤Каһвә һәм чәй дә ярдәм итә ала. Баш авырту кан басымының үзгәрүенә бәйле булса бигрәк тә.

➤Имбир ялкынсынуга каршы һәм антигистамин үзлекләре ярдәмендә баш авыртуны баса ала. Аны кушып чәй пешерергә, маринадланган имбир ашап куярга була.

➤Икенче икмәк – бәрәңгедә калий күп. Ул, үз чиратында, шулай ук баш авыртуны баса. Бер үк вакытта бәрәңге организмны сусызланудан да саклый.

➤Майлы балык та файдалы. Ашау белән ашау арасында тәнәфес зур булса, кайбер кешеләрнең башы авырта башлый. Майлы балыктагы файдалы кислоталар исә мондый «ачлык авыртулары»н булдырмый.

Үзем сынадым

Шикәрне төшерә

Соңгы арада шикәрем югары. Гел дару эчкәнче дип, түбәндәге ысулны кулланып караган идем, файдасын күрдем. Төнәтмәне ясау өчен, 25 грамм нарат җиләге яфрагына 25 грамм тигәнәк тамыры кушып, термоска саласың да шуның өстенә 200 мл кайнап торган су коясың. Шуны 2 сәгать дәвамында төнәтәсе булачак. Әлеге төнәтмәне ашар алдыннан көненә 3–4 тапкыр берәр аш кашыгы кабып куярга кирәк.

Тиз аруны җиңдем

Соңгы арада тиз арый башладым. Эшкә барып, бер-ике сәгать узгача, үземне вагон бушаткандай хис итә идем. Бер ай элек шушы ысулга юлыктым, әле дә булса файдасын күрәм. Бер стакан сөткә бер чәй кашыгы ромашка салып, утка куям да кайнап чыкканнан соң 10–15 минут сүрән утта тотам. Суынгач, сөзеп алам. Катнашмага бер аш кашыгы бал салып, йокларга кырык минут кала эчәргә кирәк. Тиз аруның нәрсә икәнен онытa барам, Аллаһка шөкер!

dreamstime.com

ВӘСИЛӘ апагыз. Мөслим

Киңәш-табыш

Тырнакны ныгыта

Тырнаклар зәгыйфьләнсә, балавызны җылытып, бармак очларын шунда батырырга, ә тырнакларда катып калган балавызны иртәнгә кадәр сакларга тырышырга кирәк. Тырнакларга даими рәвештә кара карлыган, аш серкәсе, мүк җиләге согы сөртеп торсагыз, алар нык һәм матур булып үсәрләр.

Чамасын белү кирәк

Сары мәтрүшкә һәр өйдә булырга тиеш, ди белгечләр. Бу үлән, гадәттә, тынычландыргыч дарулар, хатын-кызлар өчен чыгарылган махсус препаратлар составында очрый. Сары мәтрүшкәнең салкын тигәндә, гастрит, колит, сары кайнау вакытында да файдасы зур. Әмма күпкә киткән очракта ул аллергия китереп чыгара, артериаль кан басымын күтәрә. Сары мәтрүшкә организмдагы файдалы химик элемент һәм кушылмаларны да юк итәргә мөмкин.

wikipedia.org

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Укучы киңәше

Алмагачны коткарабыз

Алмагачларның яфрагы коелгач, аларның ботакларындагы лишайникларга игътибар итми калып булмый. Аннан котылуның әллә нинди ысулларына тотынганчы, башта аны чистартуың хәерле. Капрон яки тимер щетка ярдәмендә агачның кайрысына зыян китерми генә лишайниктан арындырабыз. Әлеге урынга 5 процентлы тимер купоросы сөртәбез. Үзем сынаган иң яхшы ысул шушы, сез дә шулай итеп карагыз әле.

Зөлфия ДӘҮЛИЕВА. Мамадыш

Камырга шикәр кирәк

Итле әйбер пешерү өчен әзерләнә торган камырларга да һәрчак шикәр комы кушам. Чөнки андый камыр тәмлерәк һәм пешкәндә төсе дә матур – кызарыбрак тора.

Сидария МУРАТШИНА

ЧҮП ТҮГЕЛ, АШЛАМА!

«Маймыл ризыгы» дип шаяртып әйтсәләр дә, бананны өлкәннәр дә бик яратып ашый. Ә менә аның кабыгын чүп чиләгенә ташлаганда, файдалы ашлама була алуы турында башыбызга да китермибез. Аннан менә дигән табигый ашлама ясап була икән бит!

Бай булганга кулай

Кайчандыр кунак ризыгы булып саналган бананны хәзер эзләп азапланасы юк, аны базарда, һәр супермаркетта табарга була. Химик составын карасаң, «файдалымыни?» кебек сорауларга урын калмый. Бананда клетчатка, калий, кальций, магний, фосфор, В группасы витаминнары һәм С витамины бар. Ул табигый антидепрессант булып санала, энергия чыганагы да булып тора. Ә аның бакчачылар, гөл үстерергә яратучылар тарафыннан киң кулланылуы шулай ук аның химик составына бәйле.

Калий – үсемлекләрне тукландыру өчен мөһим элементларның берсе. Ул үсемлекләрнең авыруларга һәм корткычларга каршы торучанлыгын арттыра. Калийдан башка фотосинтезны күз алдына да китереп булмый. Шулай ук ул үсемлекләрнең табигатьтәге үзгәрешләргә «иммунитет»тын да булдыра. Кыскасы, калий үсемлекләр үсеше өчен иң кирәкләләр рәтеннән.

Фосфор – үсемлекләрне тукландыра торган элементларның берсе. Ул матдәләр алмашы, сулау һәм фотосинтез процессларын тәэмин итә. Фосфор тамырларны ныгыта, шулай ук орлык һәм чәчәкләр өлгереше өчен дә әһәмияте зур. Үсемлекләрнең чәчәкләре булмаса яисә зәгыйфь булса, фосфор җитмәү сәбәп булырга мөмкин.

Кальций исә су әйләнеше өчен җаваплы. Тамырларга файдалы, макро- һәм микроэлементлар үзләштерелү өчен дә нәкъ менә ул җаваплы.

Магний хлорофилл барлыкка килү, ягъни сулау һәм фотосинтез процесслары өчен кирәк.

Ашлама ясау ысуллары

Чи ашлама. Яңа гына чистартылган банан кабыгын юарга һәм корытырга. Аны кайчы яки пычак белән вакларга. Үсемлек яки гөл утыртасы савытның туфрагына 10 сантиметр тирәнлектә салып калдырырга. Өстенә гөл яки үсемлекне утыртырга.

Коры ашлама. Банан кабыгын коры ашлама буларак та кулланырга мөмкин. Моның өчен банан кабыгын сушилкада киптерергә. Аннары кофе ваклагычта яки блендерда вакларга. Әлеге коры ашламаны туфрак белән бутап, үсемлекләр һәм гөлләр утыртырга яки юка гына итеп, төпләре әйләнәсенә сибеп чыгарга мөмкин.

Файдалы төнәтмә. Өч банан кабыгын яхшылап юарга һәм вакларга. Кабыкны пычак белән турарга яки блендер ярдәмендә изәргә. Изелгән кабыкны 3 литрлы банкага салып, өстенә кайнар су коярга. Караңгы урында 1–2 көн тотарга. Әзер төнәтмәне гөлләр һәм үсентеләр төбенә 1:2 исәбеннән су белән болгатып сибәргә. Ашлама ясаганда, бананның ике башын һәм сабагын кулланмаска киңәш ителә.

Компост. Банан кабыгына, башка яшелчә һәм җиләк-җимеш кабыклары, йомырка кабыгы, чәй төбе салып, исне чыгармый торган герметик савытларга салып тотарга. Әлеге «тәмлүшкә»не бигрәк тә гөлләр ярата.

Санап үтелгән чаралар тукландыру чарасы булудан тыш, туфрак составын яхшыртырга да сәләтле.

Елларда әзерләгез

ҮРДӘК ҺӘМ КАЗ МУЕНЫННАН ТУТЫРМА

Тәския ВӘГЫЙЗОВА рецепты

Үрдәк һәм каз муеннарыннан тутырма ясыйлар икән, кызларегетләр! Шуны яңа белдем. Ә сез белә идегезме? Шаккаттым!

Муенны җәрәхәтләми һәм ертмый гына кисеп алырга. Бик җайлы чыга икән тиресе, сөяк өлеше кала. Аннары үрдәк, казның эч-башын иттарткычтан чыгарырга, майлы эчәкне дә юып кушарга була. Суган, сарымсак, Адыгея тозы, төелгән кара борыч кушып, фаршны суккалап, болгатып, бер мәсьсага әверелдерергә.

Дөге бүрттереп кушсагыз ярый. Эчәк формасындагы муен тиресенә әлеге массаны тутырып, ике башын тегәргә.

Кишер кайнатмасы

Гөлсирә ШАКИРОВА рецепты

2 кг кишерне ваграк шакмак итеп турыйм. Шуңа 1 кг шикәр комы салып болгатам һәм шул килеш суы чыкканчы тотам. Шуны бик акрын утта кайнатам. Шуңа кабыгы белән шакмаклап туралган ике әфлисун өстәп кайнатып чыгарам. Бик тәмле була. Бәлеш эчлеге өчен дә менә дигән!

БИК ТӘМЛЕ ТУШЕНКА

Гөлсинә ЯКУПОВА рецепты

Тушенканы яңа чалган иттән генә түгел, туңдыргычтан алып, пычак белән кисәрлек булып йомшарган иттән ясасаң да тәмле була.

Итне артык зур булмаган кисәкләргә турыйбыз. Ярты литрлы банкага өч кара борыч, бер лавр яфрагы салабыз. Бер банкага ярты чәй кашыгы тоз җитә, аны икегә бүлеп, бер өлешен – бераз итне тутыргач, калганын өскә салабыз. Итләрне артык тыгызламыйча тутырабыз.

Банкаларны фольга белән, ялтыравыклы ягын өскә калдырып, каплыйбыз. Духовканы кабызуга, мичкә тыгабыз.

Итләр кайнап чыкканнан соң, утны киметәбез. Акрын утта ике сәгать ярым пешерәбез. Шулпалырак тушенка яратучылар сөякле итне озаклап кайнатып (тушенка әзерли башлаганчы утыртсагыз, җитешә), әзер тушенка өстенә сала ала. Бераз туң май эретеп тә салырга була.

Стериль капкачлар белән каплыйбыз. Тушенкалар искиткеч тәмле килеп чыга, мәшәкатьле кебек тоела гына, эшләргә бик уңайлы.

АВЫЗЫҢНЫ УЙЛАП АЧ

islam.ru

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһның ачуын үз өстегезгә алып, җәһәннәмнең интегүләрен үзегезгә якынайтып, бер-берегезгә карата ләгънәт, каргыш кылмагыз», – дигән. Бу сүзләрнең ни дәрәҗәдә хак булуын һәркайсыбыз аңлый. Әмма көндәлек тормышыбызда моның нәкъ киресен чагылдырган мисаллар да шактый очрый. Каргышка дучар булмас өчен ни эшләргә?

«Ихлас» мәчете имамы Мөдәррис ГЫЙМРАНОВ белән шул хакта сөйләшәбез.

:: Ни өчен каргыш ике яклы була, диләр? Гомумән, ислам дине каргыш, рәнҗешкә нинди мөнәсәбәттә?

– Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә: «Әгәр сезне рәнҗетсәләр, үпкәләтсәләр, кыерсытсалар, шулай ук җавап кайтара аласыз. Әмма кем гафу итте – ул инде яхшырак гамәл кылды», – дигән. Шуңа күрә каргыш, рәнҗеш ислам динендә мөмкин. Әмма аның шундый якларын да истә тотарга кирәк. Үпкәләргә дә мөмкин. Әмма өч көннән артык кардәшеңә үпкә саклап йөрү ислам динендә хупланмый. Көннәрдән бер көнне Рәсүлебезгә кешеләр: «Йә, Аллаһның илчесе, мөшрикләргә табынучыларның Аллаһы Тәгаләдән каргалуын сора әле!» – диләр. Рәсүлебез: «Дөреслектә мин каргыш ясаучы буларак түгел, галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән», – диде. Каргыш мәсьәләсендә сак булырга кирәк. Чөнки Рәсүлебез: «Кем дә кем кемне дә булса каргаса, ул каргыш башта каргалган кешегә барыр. Әгәр лаек булса, ул аңа төшәр. Лаек булмаса, күккә менәр. Күк кабул итмәс, җиргә төшәр һәм каргаган кешенең үзенә әйләнеп кайтыр», – диде. Шуңа күрә кемнедер каргаган, кемгәдер рәнҗегән вакытта без моның бик хәтәр әйбер икәнен белергә тиеш. Шуңа күрә каргыш ике яклы була дип әйтәләр дә. Рәсүлебездән бер кеше килеп сорый: «Йә Рәсүлуллаһ, минә минем ике колым бар. Алар миңа ялганлыйлар, миннән гел качалар. Шуның өчен мин аларны җәзалыйм», – дигән. Пәйгамбәребез шулчак: «Әгәр дә синең җәзаң аларның эшләгән гамәлләренә бәрабәр булса, сез исәп-хисап ясадыгыз. Әгәр син арттырып җибәрсәң, Кыямәт көнендә алар синнән аның өчен сорарлар», – диде. Шуңа күрә каргыш, рәнҗеш – тел гөнаһының берсе. Ул – безнең җәһәннәмгә керүебезнең иң төп сәбәпләренең берсе. Рәсүлебез бер хәдисендә: «Җәһәннәмгә күбрәк зина һәм тел гөнаһлары аркасында керерләр», – дигән.

:: Каргыш җиде буынга кадәр төшә, диюләре дөресме?

– Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгалә шундый вакыйганы китерә. Анда Муса галәйһи вә сәлләм белән Хозер кыйссасы бар. Аллаһы Тәгалә Муса галәйһи вә сәләмгә Хозер белән барып, гыйлем өстәргә куша. Хозер: «Нәрсә генә күрсәң дә, миннән сорама», – дип кисәтеп куя. Авылны чыккан вакытта Хозер бер койманы төзәтеп куя да Муса аннан: «Бу койманы ник төзәттең?» – дип сорый. Хозер аңа: «Менә бу йортта ике ятим бала яши. Аларның әти-әниләре үлгән. Ләкин алар, үләр алдыннан, анда балалары өчен хәзинә яшереп калдырдылар. Әгәр мин моны төзәтмәсәм, бу хәзинәне башка кешеләр алып, ул балаларга насыйп булмас иде. Аларның әтиләре хәерле, изге кеше иде. Шуңа күрә без ул балаларны калдырмадык», – дип аңлата. Шуңа күрә ата-анасы яхшы булу аркасында балага игелек эләгергә дә, киресенчә, аларның начарлыгы аркасында каргыш төшәргә дә мөмкин. Бу тел гөнаһының ни дәрәҗәдә зур гөнаһ икәнен тагын бер кат раслый.

:: Кайчак кеше кирәксә-кирәкмәсә дә: «Мин сиңа рәнҗим», – дип әйтеп куя. Күпләр моны үпкәләгәнне белдерү өчен бер сүз итеп кенә кабул итә. Чынлыкта «рәнҗим» дигән сүз мәгънә ягыннан шул ук «каргыйм» дигән сүз белән бер үк дәрәҗәдә түгелме? Кеше үзе дә белмәстән сине каргаган булып чыгамы?

– Моңа иң беренче чиратта кешенең шул сүзне әйткән вакытта нияте нинди булу мөһим. Хәтта Рәсүлебез бер хәдисендә: «Һәрбер гамәлгә бәя нияткә карата бирелер», – диде. Әгәр «рәнҗим» дигәндә кешенең, дөрестән дә, каргау нияте булса, ул, чынлап та, каргыш булып санала. Андый нияте юк икән, ул бәддога булмаячак.

:: Үсемлек, хайваннарның да каргышы төшә аламы?

– Без моны тәгаен генә әйтә алмыйбыз. Әмма без беләбез: мөселман хайваннарга карата бик сак мөнәсәбәттә булырга тиеш. Хәтта Рәсүлебез корбан чалырга җыенган бер кешенең мал янында пычак кайраганын күреп ала да: «Нишләп син моны алданрак эшләмәдең?» – ди. Динебез малга, хайваннарга әнә шундый яхшы мөнәсәбәттә. Кыямәт көнендә хайваннарны рәнҗеткән өчен дә җавап бирәсе булачак. Бүген этләрне, мәчеләрне чыгарып аталар, караусыз калдыралар, үтерәләр. Андый аяныч очраклар бик күп. Бу – бик зур гөнаһ. Ник дигәндә, алар – безнең әманәт. Әгәр без аларны тәрбияләргә ышандырып алганбыз икән, бу эшне ахырына кадәр җиткерергә тиеш. Моңа салкын карарга ярамый.

:: Каргыштан саклану өчен ниләр эшләргә кирәк?

– Каргыштан саклану өчен, беренчедән, кешене каргамаска кирәк. Кешене каргатырлык итеп кыерсытудан да сакланырга кирәк. Әгәр шулай булып чыккан икән, тәүбә итәргә, рәнҗеткән кешеңнән барып гафу үтенергә кирәк. Аллаһы Тәгалә каршында да тәүбә итәбез һәм башка бу эшкә әйләнеп кайтмыйбыз. Чөнки намазлар укып, уразалар тотып та, синең телең, кулың тыелмаса, бармагың тик тормаса, гөнаһлы булачаксың. Социаль челтәрләрдә кешегә теләсә нәрсә, ямьсез комментарийлар язу да хәзерге заманда каргышка илтүче юлларның берсе булып тора. Шуңа күрә алардан да сакланырга кирәк.

Гыйбрәт ал!

Акылына, әдәбенә карап

Локман Хәкимнең хатынының аягы зәгыйфь икән. «Син – акыл иясе, ни өчен кимчелекле хатын алдың?» – дип сораганнар.

– Хатын-кыз ирдән күркәмлектә, байлыкта, нәселдә – кимрәк, тәкъвалыкта артыграк булса хәерле. Күп вакыт чибәр хатын иргә түгел, ир аңа хезмәт итә, ир хатын колына әйләнә, – дип җавап биргән. Акыллы кеше хатынны чибәрлегенә түгел, акылына, әдәбенә, тәкъвалыгына карап сайлый.

(«Локман Хәким нәсыйхәтләре» китабыннан)

shutterstock.com

Хикмәтле сүз

● Үзен мал-мөлкәт хуҗасы дип фикер йөрткәннәргә Аллаһы Тәгаләнең үтә нык ачуы килер, чөнки Аллаһныкы булмаган бүтән милек җиһанда юк.

Йәгез, бер дога!

БОРЫННАН КИЛГӘН КАННЫ ТУКТАТУ ӨЧЕН

«Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим. Үә кыйлә йәә әрдубе-ләгин мәәәә яки үә йәә сәмәәәә ү әколиги. Үә гыйдаль-мәәә ү үә кудыийәл-әмр».

Мәгънәсе: «Мәрхәмәтле вә рәхимле Аллаһ исеме белән (башлыймын). Һәм әйтелде (Аллаһ тарафыннан):
– Әй, Җир, суыңны йот. Әй, Күк, суыңны туктат, – диелде. Су кими башлады. Эш тәмам булды».

ШӨКРАНА ДОГАСЫ

«Бисмилләһир-рахмәнир-рахим. Әлхәмду лилләәһи Раббил галәмиинә галәә нигмәтил иймәән. Әлхәмду лилләәһи Раббил галәмиинә галәә нигмәтил исләәм. Әлхәмду лилләәһи Раббил галәмиинә галәә нигмәтил Куръәән. Әлхәмду лилләәһил ләзии җәгәләнәә мин үммәти сәййидил мурсәлиин. Үә нәшкүруһү галәә мәә һәдәәнәә сәбиилә әһлил иймәәни үәл йәкыйин».

Мәгънәсе: «Бисмилләһир-рахманир-рахим. Иман нигъмәтенә Аллаһка шөкер! Ислам нигъмәтенә Аллаһка шөкер! Коръән нигъмәтенә Аллаһка шөкер! Безләрне расүлләр әфәндесе Мөхәммәд (галәйһи вә сәләм) өммәтеннән булдырганына Аллаһка шөкер! Һәм дә безләрне иман вә нык инану әһеле юлыннан тугры итеп алып барганына без Аңа шөкер итәбез!»

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ӘЛЕГЕ БИТТӘ КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ, ДОГАЛАР БУЛУ СӘБӘПЛЕ, КАДЕРСЕЗЛӘМӘВЕГЕЗ СОРАЛА

Мин = милләт

Асыл

ӘДИЛӘ МӨБАРӘКОВА, БАШКОРТ, 30 ЯШЬ

Миндә башкорт каны да, татар каны да ага. Чөнки әнием – башкорт, әтием – татар. Балачагыбыз, җәйге һәм кышкы каникуллар Башкортстандагы авылда уза иде. Аңлы яшькә җиткәч, үземдә башкорт тамырлары өстенлек итүен аңладым, милли үзаңым үзгәрде. Башкортстанның матур урыннары буйлап 3 көнлек сәяхәттән соң булды бу хәл. Шуннан соң **БАШКОРТ МӘДӘНИЯТЕН ТИРӘНРӘК ӨЙРӘНЕРГӘ ҺӘМ ПРОПАГАНДАЛАРГА** кирәк дигән уй туды. Тырыша-тырыша башкорт костюмы эзли башладым. Хәзер киеп йөри торган **МИЛЛИ КИЕМЕМНЕ БӨРТЕКЛӘП ҖЫЙДЫМ** дисәм дә була. Киемнәрем арасында иң кадерлесе – әдрәстән эшләнгән җилән. Миңа аны ерак туганыбыз бүләк итте. Яше дә бар, аңа инде **130 ЕЛДАН АРТЫК**.

МИН МИЛЛИ КИЕМНӘР КОЛЛЕКЦИЯСЕН ТУПЛЫЙМ. Башкорт, татар киемнәренең берничә комплекты бар инде. Башкортларга кагылышы булган барлык чараларда катнашырга тырышам.

Традицияләребез саклана, аларга хөрмәт белән карыйбыз. **КАЗАНДА ТУЫП-ҮССӘМ ДӘ, БАШКОРТ ТЕЛЕНДӘ ИРКЕН АРАЛАШАМ.** Өйдә татарча да, русча да сөйләшәм, тарихи ватаныма кайткач, башкортчам «кабына».

Телне саклау мәсьәләсе – хәзерге вакытта иң катлаулы проблемаларның берсе. Җәмгыять тә телләрнең юкка чыгуына йогынты ясамый түгел. Әмма **МИН КҮП НӘРСӘ ГАИЛӘДӘН ТОРА ДИП САНЫЙМ**.

Хәзерге вакытта мин – биш яшьлек бала анасы. Ни кызганыч, кызым да күбрәк рус телендә сөйләшә. **БАР КӨЧЕМ БЕЛӘН, ИҖАТ АША БУЛСА ДА, ТЕЛГӘ, МИЛЛӘТКӘ МӘХӘББӘТ СЕҢДЕРЕРГӘ ТЫРЫШАМ.**

Әдилә – фольклор буенча укытучы, этномузыколог. «Мәктәптә балалар белән эшләгән вакытта да тел мәсьәләсенә игътибар бирми калмыйм. Алар белән төрле телләрдә җырлыйбыз. Балаларның да, ата-аналарның да башка халыкларга, аларның мәдәниятенә булган ихтирамын күрү сөендерә», – ди Әдилә. Гомумән, аның тормышы һәм яшәеше иҗат, халыклар мәдәниятенә бәйле. «Zakaria» фолк-төркеме солисты да ул.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде. Фото: Анна АРАХАМИЯ

8 ноябрь | Чәршәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10, 02.05 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «Алмаш» 16+
11.00, 00.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «Департамент» 16+
13.00, 00.25 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Азбука долголетия» 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я» 12+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.30 «Әдәби хәзинә» 6+
18.00 «Гаилә учагы» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Ватандашлар» 16+
23.00 «ИСЧЕЗНУВШАЯ» 16+
01.15 «Кәмит Җәмит» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Башваткыч» 12+
05.35 «Онытa алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 18.20, 23.10, 05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+
09.30, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 21.25 «Кунак БиТ шоу» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
19.10, 22.20, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00, 00.15 «Гаилә учагы» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
– Бу эшләргә җәмәгатем Рәшидә абыстай илһамландырып торды. Бик күп эшләрдә терәгем булды. Коронавирус дигән яман чирне генә җиңә алмады. Бу зәхмәт авылыбыз өчен янып йөргән, һәрчак ярдәм итеп торган асыл егетләребез Рафикъ һәм Равил Бәхтияровларның да вакытсыз гомерен өзде, – дип көрсенә Әнәс хәзрәт.

Абыйлы-энеле Бәхтияровларны авыл халкы горурлык катыш рәхмәт хисләре белән искә ала. Аларның туган авылларына эшләгән игелекләре санап бетергесез. Эшмәкәр Рафикъ Бәхтияров иң элек Бакырчыга күпер салдырган.

– Авылны республика юллар программасына кертеп, асфальтлы итәргә дә булышты ул. Авыл уртасында тагын бер күпер төзетте. Балалар мәйданчыгы, хоккей тартмасы булдыруда башлап йөрде. Бәхтияровлар көче белән авылыбыз җирдә ай дигәндә өр-яңа мәчетле булды. Әниләре хөрмәтенә яңа мәчетне «Суфия» дип атадылар. Апалары Әлфия авылыбызга бүген дә ярдәм итеп тора. Әле менә яңа гына мәчетнең керә торган өлешен түбәләтте ул. Юкса, мәчетнең биек баскычлары кыш көннәрендә бозга катып, бабайлар берара намазга да йөри алмый башлаган иде, – ди Әнәс хәзрәт.

Тау башында әллә кайдан балкып торган шушы мәчет бүген авыл халкын берләштереп, күңелләренә нур индереп торган иң рәхәт урыннарның берсенә әверелгән. Биредә авыл халкы өчен дин сабаклары да оештырыла. Балалар арасында да мәчеткә йөреп, дини белем эстәүче сабыйлар шактый. Бүген авылда башлангыч мәктәп эшли. Анда 11 бала белем ала.

Коечылар авылы

Бакырчы – элек-электән кое казучылары белән данлыклы авыл булган. Колхозда эш туктап торган кышкы озын көннәрдә авылдагы ир-атлар, төркем-төркем булып, кое казырга чыгып киткән. Күрше-тирәне генә түгел, чит төбәктә яшәүчеләрне дә коелы иткән алар. Элек авылда һәр хуҗалыкта кое булган. Бүген шуларның өчесе генә сакланып калган.

Бәхетебезгә, шушы елларның тере шаһиты, гомерен әлеге авыр хезмәткә багышлаган аксакал Фәрданша Салихов белән безгә дә күрешергә насыйб булды. Әле бу көннәрдә генә 79 яшен тутырган оста безне керә-керешкә бакча артындагы коесы янына алып барды. Өйгә су кергән булса да, малларга, бакчага суны биредән ала икән алар. Әлеге коены 1994 елда ук казыган ул. Тирәнлеге – 14 метр. Фәрданша абый казыган иң тирән кое исә 21 метр булган. Үз гомерендә ничә кое казыганын санамаса да, «Кое казый-казый Әмрикәгә чыгып җиттем инде», – дип шаярта җор телле аксакал.

– Утыз елдан артык авылда механизатор булып эшләдем. Кышын кое казырга китә идем. Нәселдән-нәселгә күчкән һөнәр бу. 16 яшемдә кое казый башладым инде мин. Аннан да авыр хезмәт юктыр ул. Гомер буе кул белән казыдык. Хәзер мондый ысул белән эшләүче юк инде, – ди Фәрданша Салихов.

Бер коены 3–4 көндә казыган, берике атна маташкан чаклары да булган. Бар да җирнең катлыгыннан тора. Фәрданша абыйның кое казуга бәйле кызыклы истәлекләре дә шактый. Шулай бервакыт Чувашиядә эшләгәндә бер хатын бала таба алмавыннан зарланган. Фәрданша абый шулвакыт: «Менә коедан беренче тапкыр алган суны эчсәң, әни булганыңны сизми дә калырсың әле», – дип шаярткан. Кыек атып туры тидергән бит! Ике елдан шул ук гаилә аны бәләкәй сабые белән каршы алган.

Китап кына түгел

Авылдагы җирләр инвестор карамагында булганлыктан, Бакырчыда бу юнәлештә үз эшен булдырган фермерлар юк диярлек. Әмма үзләре өчен күпләп мал, кош-корт үстерүчеләр бар. Утыз елдан артык гомерен балаларга белем бирүгә багышлаган Рузилә һәм Җәүдәт Сафиуллиннар әнә шундыйлар. Гаилә башлыгы – Бакырчы мәктәбендә директор, Рузилә ханым исә күрше Акъегет авылы мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укыта. Соңгы елларда инкубаторда күпләп кош-корт чыгара башлаган алар.

– Шулай бервакыт интернетта кәгазь тартмада чебиләр чыгару турында видеога тап булдым. Озакламый үзем дә тәвәккәлләдем. Кәгазь тартмага 7 генә йомырка куеп карадым. 21 көн буе аларны көненә 4 тапкыр әйләндереп тордык. Бу эш бик кызык тоелды. Икенче елга инде инкубатор алдык. Автомат булгач, җайлы – йомыркаларны үзе әйләндерә. Ике ел элек үрдәкләр дә чыгара башладык. Быел инде каз бәбкәләре чыгарып карадык, – ди Рузилә апа. – Өченче ел инкубаторда декабрьдә чыккан 20 үрдәк белән 25 чебине идән астында үстердек. Аннары иптәшем сарайга иске шкафлардан оя ясады. Хәзер кошкортларыбыз кызыл лампочка астында шунда кышлыйлар.

Шул рәвешле инкубаторда елына 150дән артык чеби, каз, үрдәк бәбкәләре чыгаралар икән. Заказга түгел, күбрәк үзләре өчен дип эшлиләр. Сорап килүчеләр булса, сатып та җибәрәләр. Сәламәтлек булсын да, күңел үсеп, эшләп торырга гына язсын!

Сафиуллиннар кебек тырыш гаиләләр булганда, авылның киләчәге дә өметле әле. Авылда төпләнеп калуларына һич кенә дә үкенми алар.

– 1993–1997 нче елларда Бакырчы авылында яшьләр шактый иде. Күбесе гаиләле булып, авылда төпләнеп тә калдылар. Нишләптер шәһәргә китү турында уйламадык та, – ди Рузилә Сафиуллина. – Кызганыч, хәзер заманалар башка. Яшьләр дә авылда калырга атлыгып тормый. Эш юк бит, аларны да аңлап була. Ә авыл язмышы – яшьләр кулында. Нинди генә авыл булмасын, кечкенәме ул, зурмы – мәктәпне, балалар бакчаларын саклап калырга кирәк. Шул вакытта авыл яшәр.

Мал яшәтә

Яшьләр авылда калмый, дип күпме генә зарлансак та, Бакырчыда ул яктан хәлләр алай ук мөшкел түгел әле. Авылда төпләнеп калган яшьләр шактый. Аларның күбесе Казанга йөреп эшли, «Кызыл Шәрык» ширкәтендә эшләүчеләр дә шактый.

Бакырчыга тугры калган иң яшь пар – Зәринә һәм Илфат Хафизовлар да «Кызыл Шәрык»та эшләгәндә танышкан. Бер елдан кавышып та куя алар. Бүген инде Зәринә белән Илфат өч бала үстерә. Игезәкләре быел мәктәпкә укырга кергән. Күптән түгел яшь гаилә, күптәнге хыялын чынга ашырып, башка чыккан.

– Бер ел элек йорт сатып алдык. Мал асрарга яңа абзар салдык. Бүген шунда биш үгез, тавык-чебеш, үрдәкләр асрыйбыз. Авыл җирендә мал асрамыйча гына тормыш алып барып булмый. Әле «Яшь гаилә» программасы буенча чиратта да торабыз. Менә шулай кулдан килгәнчә тырышып, хыялларны акрынлап тормышка ашырып яткан мәлебез, – ди Зәринә тыйнак кына. – Авылда төпләнеп калуыбызга үкенмибез. Тырыш булсаң, бүген авылда да менә дигән итеп яшәп була. Кешенең ничек яшәве бары тик үзеннән генә тора.

Бакырчы уңганнары

Бу сүзләрнең хаклыгына инану өчен, авыл халкына күз салу да җитә. Бакырчыда кем белән генә сөйләшмә – барысының да ниндидер өстәмә эше, мавыгуы бар. «Булмый инде», – дип зарланып, кемнеңдер китереп биргәнен көтеп утырмый алар.

Газеталар турында сөйләшеп утырганда, сүз ара сүз китеп, авылның почтальоны Гөлназ Сәгъдиеваның кул эшенә дә маһир икәнен белеп алдык. Баштарак чәчкә куя торган резинка, заколкалар, алмаз мозаикасыннан матур картиналар ясау белән мавыккан ул. Соңгы арада өендә келәм тукый башлаган.

– Шулай беркөнне келәм тукый торган җайланма ясарга өйрәткән видео күреп алдым. Моның бер авырлыгы да юк бит дип, ул җиһазны агачтан җыеп та куйдым. Хәзер шунда калдык-постык җеп, тукыма кисәкләреннән кич утырып келәм тукыйм, – ди Гөлназ Сәгъдиева.

Элегрәк күңел өчен башкарылган бу эшләре хәзер Гөлназ ханымга тынычлану чарасы да булып тора. Махсус хәрби операциягә эләккән улы өчен ут йотуын яраткан кул эшләре ярдәмендә аз булса да басарга тырыша ул.

Төп эшеннән бушаган арада торт, пирожныйлар пешерүче Ләйсән Салихова, берсеннән-берсе матур чәчәк үсентеләре әзерләп сатучы, төрле материаллардан ясалма чәчәкләр ясаучы Гөлфирә Борһанова да бу эшләрне, иң беренче чиратта, күңел өчен эшләүләрен яшерми.

Бакырчының тагын бер уңган кызы Зөһрә Сәлахиеваны исә күпләр кабартма пешерү остасы буларак белә. Мәрхүм Хәдичә кодагые өйрәтеп калдырган эшне кәсепкә әйләндергән ул.

– Заказларны күбрәк ял көннәрендә алам. Бер пешергәндә иң күбе 120 кабартма әзерләгәнем бар. Соңгы арада 50–60тан артмый. Бер кабартманы 30 сумнан сатам. Бер табага 7 кабартма салам. Аларның ябышканын яратмыйм. Кабартманың бар матурлыгы да шунда, – ди Зөһрә ханым.

Тәмле кабартма пешерү серләрен безгә дә җиткерде ул.

Аны әзерләү өчен 3 стакан сөт, 1 стакан май (ниндие дә ярый), ярты стаканнан артык шикәр комы, бер чәй кашыгы өеп тоз, 7 йомырка, бер кап «Люкс» чүпрәсе кирәк булачак. Шуларның барысын бергә кушып, кулга ябышмый башлаганчы йомшак итеп кенә камыр басарга кирәк. Бер порциядән 40–50 кабартма килеп чыга.

Бакырчыда ак яулыклы әбиләр дә яшьләрдән калышмый. Фирдәүсә апа Борһаниева күп еллардан бирле как ясый икән әнә.

– Быел җәй как ясау өчен бигрәк тә яхшы килде бит. Аны тигез түбәгә куеп киптерәм. Кояш булмаганда, духовкада киптереп алам. Помидор кушып ясаган какны аеруча яратабыз. 10 литрлы кәстрүлгә алма тутырам да өстенә, зурлыгына карап, 5–10 помидор турап салам. Пешеп чыккач, блендер белән изәм дә, бераз шикәр комы салып, майланган табаларга салам. Бу эштә Хәниф картым да булыша, – ди Фирдәүсә апа.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КАРАМА ЯШЕНӘ

ЗУР ЯШЬ АЕРМАСЫ – ГАИЛӘНЕҢ БӘХЕТЕМЕ, БӘХЕТСЕЗЛЕГЕМЕ?

Мәхәббәткә киртә юк, диләр. Яшь аермалары 10–20 ел булган парларны күрү гаҗәп күренеш түгел. Мондый никах нигезендә нәрсә ята? Зур яшь аермасы – гаиләнең бәхетеме, әллә бәхетсезлегеме? «ВТ» хәбәрчесе шул сорауларга җавап табарга тырышты.

shutterstock.com

Мәхәббәтнең яше юк

– Ирем белән 23 яшемдә таныштым. Миннән күпкә өлкәнрәк булгач, башта шикләнгән идем, соңыннан ниятнең җитди булуын аңладым. Шулай күндем инде, матур гына йөреп киттек, гаилә кордык. Тик яшь аермасы безгә киртә булыр, дип уйламаган идем, – ди үзеннән 20 яшькә өлкәнрәк иргә кияүгә чыккан аңгәмәдәшебез. – Әйбәт яшибез, һәр сүземә «ярар» дип кенә тора. Тик ул – бик коры кеше. Ирләре белән күгәрченнәр кебек гөрләшеп яшәүче бәхетле парларга кызыгып куям кайчак.

Үзеннән өлкәнрәк хатынга өйләнгән ир-атны җәмгыятьтә күп вакыт аңлап бетермиләр. Хатын-кызга исә бераз гаепләп тә карыйлар.

– Яшь чакта кемдер миңа, үзеңнән 10 яшь кече егеткә кияүгә чыгарсың, дисәләр, кычкырып көләр идем, – ди Чаллыда шәфкать туташы булып эшләүче 42 яшьлек Руфия. – Ирем, көн дә артымнан йөреп, үзенә каратты. Без инде хәзер 12 ел бергә яшибез. Аның миннән яшьрәк булуының искә төшкәне дә юк. Тормышны тулысынча ирем алып бара. Гаилә бюджетын да, балаларга бәйле сорауларны да хәл итә. Мин аның сүзеннән чыкмыйм, ул да минекенә колак сала. Мәхәббәтнең яше юк аның.

Билгеле шәхесләр арасында да яшь аермасы зур булган гаиләләр күп. Шундый парларның берсе – Татарстанның халык язучысы Рабит Батулла белән Рузия Батуллина. Аларның яшь аермасы – 17 ел.

– Яшь аермасы сизелми һәм сизелмәде дә. Бер-беребез белән аңлашып, уртак фикергә килеп яшибез. Һәрнәрсәгә карашыбыз бертөрле. Көнкүрештә дә, балаларны тәрбияләү мәсьәләсендә дә шулай булды. Бер-беребезгә ярашып яшибез. Яраклашып түгел, ярашып. Яраклашып яшәү – анысы башка нәрсә. Андый парлар да бар, – дип сөйләде Рабит ага. – Рузия – белгечлеге буенча икътисадчы. Тормышта да бик төгәл ул. Ә мин гел иҗат эше белән яшәдем.

Шөкер, 40 елга якын бергә матур гына яшәп ятабыз.

Сөйләшүгә Рузия апа да кушылды:

– Яшь ир белән торып карамагач, мин аның нәрсә икәнен белмим. Мин кияүгә соңарып кына – 31 яшем тулгач чыктым. Яшь аермасы зур булганы сизелми. Хәзер бигрәк тә. Чөнки ул иҗат белән яшәде һәм яши, гел хәрәкәттә. Аңлашып яшәдек, вак-төякне җиңел генә уздырып җибәрсәң, тормыш үз көенә бара инде ул.

Татар эстрадасы җырчылары Салават Миңнеханов һәм Гүзәлемнең яшь аермасы – 13 яшь. Салават Миңнеханов фикеренчә, бу берничек тә бәхеткә киртә була алмый.

– Яшь аермасы гаилә тормышында бөтенләй сизелми. Бер каршылык та юк. Аңлашылмаучанлыклар була, әмма алар әллә ни җитди түгел. Фильмнар мисалында карыйк. Әйтик, «Звездные войны» фильмы хакында фикер алышып булмады. Гүзәлем аны белми. Менә шунысы бар, – ди җырчы, уенын-чынын бергә кушып. – Яшь хатын яшәртә дә, картайта да, чәчне дә агартырга мөмкин *(көлә)*. Минемчә, нинди яшьтә булуың мөһим түгел. Гаиләдә күп нәрсә хатын-кыздан тора. Өйдәге тынычлык та, ир-атның кәефе дә. Бу хатын-кызның яшенә генә бәйле түгел.

Алтын урталык бармы?

Ир белән хатын арасындагы яшь аермасы җәмгыятьтә бәхәс тудырмый калмый инде ул. «Әтисе яшендә бит», «Кай җиренә карады икән», «Акчасына кызыгып чыккандыр» дигән сүзләрне еш ишетәсең. Кайберәүләр: «Ир белән хатын бер яшьтә булса, алар уртак телне җиңелрәк таба», – дисә, икенчеләре: «Берең тәҗрибәлерәк булу яхшырак», – ди. Алтын урталык кайда соң?

Гаилә корган парның яшьтәшләр яки ир-атның хатыныннан аз гына өлкәнрәк булуына күнеккән без. Психологлар да, ныклы гаилә булдыру өчен, ир-ат белән хатын-кыз арасындагы яшь аермасы 5–6 ел булырга тиеш дип саный.

– Психоэмоциональ яктан караганда, ир хатыныннан 5–6 яшькә өлкәнрәк булса хәерле. Алар икесе дә тигез: социаль, матди яктан да, белем дәрәҗәсе белән дә, икесенең дә тормыш тәҗрибәсе тупланган – кыскасы, бөтен яктан бер-берсенә туры киләләр. Болар барысы да ныклы гаилә нигезе булып тора. Социологик тикшеренүләр күрсәткәнчә, мондый парлар күбрәк бала алып кайта, – ди психолог Фәйрүзә Һадиева.

Яшь аермасы зур булган парларның бер-берсенә тартылу сәбәбе нидә соң? Фәйрүзә Һадиева фикеренчә, андый мөнәсәбәтләр, нигездә, балачактагы күңел җәрәхәтләренә барып тоташа.

– Хатын-кыз үзеннән күпкә өлкән ир-атка тартыла икән, димәк, кызның әтисе булмаган яисә булып та, кызына җитәрлек игътибар һәм мәхәббәт бирмәгән. Өлкәнрәк ирләр тәҗрибәлерәк, акыллырак, төплерәк була. Кызны әнә шул сыйфатлар җәлеп итә дә инде, – ди белгеч. – Киресенчә дә була ала. Әнисеннән алмаган энергияне, назны егет үзеннән өлкәнрәк хатын-кыздан өмет итә.

Ләйсән САФИНА

ТАТАРСТАНДА ӨЙЛӘНЕШҮЧЕЛӘР ҺӘМ АЕРЫЛЫШУЧЫЛАР САНЫ

2023 елның 8 аенда **16264 пар** язылышкан (↘0,2 процентка кимегән).

2022 елда шул ук чорда **16301 никах** теркәлгән.

2023 елның 8 аенда **9567 пар** аерылышкан (↗0,8 процентка арткан).

2022 елда шул ук чорда **9489 гаилә** таркалган.

ФИЛҮС КАҺИРОВ:

«БЕЗНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕК – МИЛЛИ МОҢДА»

Сүздә түгел – гамәлдә. Татарстанның халык артисты Филүс КАҺИРОВ турында әнә шулай дип әйтү хактыр. Әйтик, сәхнәне чүп басты, дип зарланмый, оркестр белән җанлы концертлар куюны дәвам итә. Концертларына халык арасыннан берәр «самородок»ны чакыра. Быелгы концертлары, эстраданың уңышлары һәм чирләре, татар артистының үзенчәлекләре – без әнә шулар хакында сөйләштек.

vk.com/kagirovfilyus

:: Бүгенге Филүс ул нинди?

– Холык барыбер шул ук. Шундый ук шук, дигәндәй. Казанга килгән чак белән хәзергесен чагыштырсак, ул чактагы самимилек, беркатлылык хәзер юк инде. Гаилә коргач, җаваплылык хисе артты. Кайчак тормышның кайбер мизгелләре искә төшә дә, хәзер булса, алай эшләмәс идем, дип уйлап куям. Төптәнрәк уйлап эш итәр идем кебек. Ә икенче яктан, ничек булган – шулай булган инде. Үткәннәрне сабак дип кабул итәргә дә, алга барырга кирәк. Туган да картайган, диләр кайбер кешеләр турында. Мин андый түгел. Аннары чит кеше хаталарыннан да сабак алып була, диләр. Монысы белән дә килешмим. Үз ялгышларыңнан гына сабак алып була.

:: Без опера театрында барган репетиция арасында сөйләшәбез. «Опера» дигән төшенчә генә дә төрле сораулар тудыра. Безнең халык операны кабул итәме? Опера җырчысына аның карашы нинди? Үзеңә бу жанр ничек бирелә?

– «Сөембикә» операсына, мәсәлән, билетлар ике ай элек сатылып беткән иде. Башкаларына да шулай.

> Операны бездә үз итмиләр дип әйтеп булмый. Аның үз тамашачысы бар. Татар операсын әллә ничә тапкыр килеп караучылар да бар. Икенче мәсьәлә – татар операларының азлыгы. Күбрәк булсын иде ул. Халык сайлап барырлык булсын иде.

Мин үзем опера жанрын бик яратам. Бәлкем балачак хыялымны тормышка ашырырга ярдәм иткәнгә өчен дә якындыр ул миңа. Балачактан актер булырга хыялландым. Гаилә бәйрәме, берәр нинди мәҗлес булса, кунаклар алдына я берәр артист, я әби булып киенеп чыга һәм тамаша ясый идем. Аннары күбрәк җыр юнәлешенә өстенлек бирелде дә актерлык хыялы күмелеп калды. Консерваториянең соңгы елларында да опера җырчысы итеп күрә идем әле үземне. Опера спектакльләрендә мин бөтен мөмкинлекләремне чагылдыра алам. Бу жанрда балачак хыялымны тормышка ашырдым, дип тә әйтеп була.

:: Камал театры яңа бинага күченгәч, элеккеге бинада музыкаль театр барлыкка киләчәк. Бу хакта мәдәният министры Ирада Әюпова журналистлар белән очрашуда әйткән иде. Аның эшчәлеген ничек күрәсең?

– Бу сорауны миңа җитәкчеләр дә биргәне бар. Музыкаль театр ул – опера театры гына да, драма театры гына да түгел. Анда рок-опера да, мюзикллар да, джаз да, драма да, җыеп әйткәндә, музыкаль юнәлештәге бөтен жанрлар сыя. Мин аны хәтта төрле яшь категорияләрен колачлаган, хәтта балалар өчен дә спектакльләр куелган театр итеп күрергә телим. Әмма бер нәрсәне онытмаска кирәк: Татарстанның башкаласында музыкаль театр ачабыз икән, ул милли юнәлештә булырга тиеш.

:: Яңа музыкаль театр да «Үзгәреш җиле» кебек бер караганда үзебезнеке, икенче караганда ят булган бер күренешкә әйләнмәсме?

– Бу җәһәттән мин кузәтергә яратам. Әйтик, татар артистларын чит илгә чакырдылар, ди. Без аларга нәрсә күрсәтәбез? Әгәр милли үзенчәлекне күрсәтәбез икән, алар кызыксыначак. Чөнки мондый сәнгать, бу аһәң – аларга яңалык. Шуңа Айдар Фәйзрахманов җитәкчелегендәге фольклор ансамбле чыгышларын сокланып, шаккатып, аягүрә басып карыйлар да инде. Әмма без Америкага джаз белән барырга да күп сорамыйбыз. Яки Италиягә итальянча җыр белән. Һәм аларга бу чыгышлар, бердән, кызык түгел, икенчедән, көлке булырга мөмкин. Без чит илдә «Әллүки»ләр, милли моңнар белән генә игътибарны яулый алабыз. Музыкаль театр да милли юнәлештә булса гына кабатланмас була ала.

:: Филүс Каһиров аннан соң концертларын Камал театры бинасында гына куячакмы?

– Камал театрында мин беренче концертымны гына куйдым. Аннары төрле биналар сайларга туры килде. Бина буенча даимилек булмаса да, ноябрь минем айга әверелде. Көзен ике көн һәм язын ике көн – минеке. Даимилеккә җанлы тавышны да кертеп була. Оркестрга кушылып җырлауны бернәрсә белән дә чагыштырып булмый инде ул.

:: Нинди була быелгы концерт? Үзенчәлеге нәрсәдә?

– Концертка сайланган җырларның яртысы – миңа атап иҗат ителгән җырлар, калганы – ретро һәм халык җырлары. Бу да үзенчәлектән бигрәк даимилектер инде. Махсус кунаклар турында әлегә әйтми торыйк.

:: Узган ел концертыңда Артур Хәсәнов катнашкан иде. Аның белән элемтәгез бармы?

– Без аның белән гел элемтәдә. Ул – гап-гади авыл егете. Моңлы егет. Андый кешеләрне сәхнәдән күрсәтәсем, безнең арада менә нинди талантлар бар, дип халыкка танытасым килә. Шуңа күрә бер елны концертыма дальнобойщик Равил Галиевне чакырдым. Концертта катнашырга чакырып шалтыраткач, ышанмый торды әле. Аннары Эдуард Асаповны чакырдым. Ә Артур белән танышу болай булды. Өлешчә мобилизация игълан ителгәч, аның башкаруында «Киек каз юллары» дигән җыр видеосы таралды. Ул видеоны миңа кем генә җибәрмәде. Башта мин Артурны солдатлар янына чыгыш ясарга гына чакырганнар дип уйладым. Ә ул Пензада «учебка»да булган икән. Кыскасы, башта социаль челтәр аша эзләп таптым, аннары телефон номерларын алыштык. Якташ, Башкортстаннан икән, Илеш районыннан. «Мин Уфада концерт куям, әти-әниеңнең мөмкинлеге булса, килеп карасыннар, анда сине дә искә алам», – дидем. Әти-әнисе килде, аннары инде Казандагы концертта үзе дә катнашты. Тамашачы бик яратып кабул итте аны.

:: Нәрсә генә эшләсәң дә, хейтерларың уяу. Шунда ук киресен сукаларга тотыналар.

– Аңлаган кешегә аңлатып торуның хаҗәте юк. Аңламаган кешегә, маңгаеңны ташка бәрә-бәрә аңлатсаң да, файда булмаячак. Чөнки ул сине ишетми. Аның үз туксаны туксан. Берзаман бу турыда Салават абый белән дә сөйләшкән идек. Аңларга теләмәгән кешегә аңлатырга тырышып интегергә кирәкми. «Бал корты бит чебенгә, бал б…тан тәмлерәк, дип аңлатып тормый, үзенекен эшли», – дидем. Ул аны концертларында да сөйли башлады бугай инде. Бу уңайдан сиңа тагын бер мәзәк. Юл буйлап пычракка баткан чучка бара икән. Каршысына фил очраган. Теге фил, юл читенә чыгып, чучканың үтеп киткәнен көткән. Чучка шуннан соң батыраеп, күрдегезме, миңа фил дә юл бирде, дип мактана икән. Моңа филнең дуслары бик аптыраган, син нишләп аңа юл бирдең, дип сораган. Фил, пычранасы килмәде, дигән. Ачу килгән вакытлар була инде. Кайчак, минем бит ният андый түгел, дип бәхәсләшәсе, бик аңлатасы килә. Шунда шушы мәзәк искә төшә дә тынычланам. Дөньяда яхшылык пычраклыкка караганда барыбер күбрәк.

:: Синең пародияләр ясау осталыгың да бар бит әле. Үпкәләмиләрме аңа? Бу сәләтне тагын да үстерергә уйлыйсыңмы?

– Сәхнә артында мин гел шул пародия белән яшим. Ул табигатемдә, бүтәнчә булмый да. Концерт вакытында да җае туры килсә, Салават абый кебек, Айдар абый кебек сөйләп алам. Рөстәм Закиров кебек җавап биргән бар. Бу – дусларча шаяру инде. Пародия – нормаль күренеш. Кешенең үзенчәлеген эләктереп алып, күпертеп күрсәтү. Әмма бөтен кешенең дә кабатланмас үзенчәлеге булмаска да мөмкин.

:: Эстрадада юмор-пародия ни дәрәҗәдә?

– Татар КВНщиклары үсеп килә, шуңа шатланам, үземнең дә «Йолдызлы номер»да катнашканым булды. Бик талантлы яшьләр бар. Тел, тел, дибез. Телнең матурлыгы, җорлыгы менә шушы яшьләр кулында. КВН безгә бик туры килә ул. Татарның хәйләкәрлеге, тапкырлыгы нәкъ менә шунда чагыла.

Блиц-сораштыру

– Гаилә синең өчен ул – ...
– терәк. Яшәү мәгънәсенең бер өлеше.

– Улларыңа әйтер сүзең?
– Әгәр улларым бу газетаны 10, бәлки 20 елдан соң кулларына алса, мин аларга 2023 елда, октябрьнең 26 нчы кичендә сөйләшкән сүзне искә төшерергә кушар идем. Ул кичтә 6 яшьлек улым: «Ничек итеп мәңге яшәп була?» – дип сорады. Аның яшендә олысы да, үлемсезлек даруы уйлап табам, дип хыялланган иде. Күрәсең, алар шушы яшьтә әтисе белән әнисенең кайчан да булса бу дөньядан китеп барачагын аңлый башлаган. Шуннан без үлем, җәннәт турында сөйләштек. Җәннәткә эләгер өчен яхшы кеше булырга, беркемне рәнҗетмәскә, игелекле булырга, яхшылыклар кылырга кирәк дигәнне ишетүгә, улым идәнгә чәчелгән карандашларын җыеп куйды. Менә 10 елдан, 20 елдан соң сорармын: «Ничек соң, фикерләрегез үзгәрмәдеме?»

– Бүгенге кәефеңә нинди җыр туры килә?
– «Күңелеңә авыр алма».

:: Мөмкинлек бирсәләр, сәнгатьтә нәрсәне үзгәртер идең?

– Сәхнәдә профессионаллар эшләвен теләр идем. Хәзер эстраданы түбән итеп күрәселәре килә. «Нәрсә инде ул шунын кадәр?!» – диләр. Ә бит эстрада – иң популяр җанр. Аны халыкның киң катлавы карый, бу – бик зур мөмкинлек. Шуңа күрә мин концертларны аз куям, әмма җентекләп әзерләнәм. Беренче концерттан ук чыгышларны оркестр белән башкарам. Андый музыканың тәэсире бермә-бер зур. Хәзер карыйм: бик күп җырчылар, оркестр ук булмаса да, сәхнәгә музыкантларны чыгара башлады. Мин моңа сөенәм. Акрын гына булса да, сәхнәнең дәрәҗәсе күтәрелә дигән сүз. Әйе, бу бик чыгымлы. Музыкантлар белән бергә сәхнәдә дистәдән артык кеше эшлибез. Моннан тыш сәхнә бизәлеше, техникага таләпләр дә үзгәрде. Әйтик, артында экран эшләп тормаса, синең концерт фәкыйрь санала. Менә шушы чыгымнарны каплар өчен, ким дигәндә ун көн рәттән концерт куярга кирәк. Шуңа да бит хәзер 25–30ар көн рәттән концерт куялар. Мин үземнең «подача» белән 25–30 көн концерт куя алмыйм. Җыр яздыруда да талымлы мин. Аранжировка белән рәхәт ул. Флешкаңны бирәсең дә студиягә кереп җырлап чыгасың. Ә ансамбль белән яздырганда, һәрбер уен коралын аерым яздырырга кирәк. Шундый студия эзлибез әле менә.

:: Иң зур телəгең нинди?

– Теләк, бәхет кебек үк бәләкәй теләкләрнең җыелмасыдыр, мөгаен. Шуңа күрә, иң зур теләгем – менә шушысы, дип аерып әйтә алмыйм. Дөнья тыныч, иртәгәге көнгә ышаныч булса иде, дип телим. Бу – һәрбер кешенең калебендәге теләктер. Мин бәрәкәтнең хәрәкәттә булуына инандым. Шуңа күрә гаиләм белән сәяхәт итәсем, дөнья күрәсем килә. Юкса, үлеп китсәм, дөнья да күреп булмады, дип әйтүчеләрне шактый ишеткән булды.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

НӘБИРӘ ГЫЙМАТДИНОВА

ШУНДЫЙ ИНДЕ БЕЗ...

(Бәян)

< Дәвамы. Башы 15, 22, 29 сентябрь, 6, 20, 27 октябрь саннарында

– Мин – Илдус, – диде ул.

– Ильяс, – диде егет.

– Мәрьям, – диде кыз.

– Сәяхәткә җыендыгызмы әллә? – Мирзам яңа танышларын хәзер үк кармак очына элэктерергә тиеш иде. Дөнья – дәрья, «балык»лар аска чумса, кайдан эзлисең ди!

– Юк ла, абый. Сөремле шәһәр һавасыннан туеп, без дүрт ел рәттән җәйге айларда Сөлчә елгасы буенда палатка корып яшибез! Балык тотабыз, уха пешерәбез, дару үләннәре киптерәбез. – Мәрьям нур сибеп балкый, әйтерсең аның йөзе май кояшы иде. Урыныбыз иркен, кунакка рәхим итегез, Илдус абый.

– Килештек, – диде Мирзам – Илдус. Чынлыкта, килеште микән? Бая гына: «Кораб чакырт та төяп озат боларны!» – дип ашкынган иде, ә хәзер әлеге уен күңеленнән аркылыга-торкылыга сызды. Нидер сагайта иде, нидер... Яшьләргә җан тартылмый иде, җан... Гаҗәп!

Батрак-робот сөргән йортның такта капкасы төрле төсләргә буялган йолдыз бизәкләре белән чуарланган иде. Монда хыялый бала-чага тора бугай дисә, ялгышты Мирзам, хуҗасы ак сакаллы Хәсән карт чирәмгә тараткан бәрәңге өемендә казына иде.

– Алла куәт бирсен! – Егет эш белән мәшгуль татайны ни рәвешле сәламләргә икәнен белә иде.

– Бирсен, бирсен, – диде карт.

– Сатлык бәрәңгеме, бабай?

– Чәчүлек. Үрдердем.

– Булышыйммы, бабай? – Ул ничек тә карт белән элемтә чылбырын ялгарга тиеш иде.

– Булышма, бәбәгеп имгәтерсең җә. Үрмәкүч сөрә дә, чәчә дә.

Мирзам үрелеп-үрелеп бакча ягына карады. «Үрмәкүч» үткен теше белән җир катламын актара да артыннан биш җәпле тырмасын төшереп, туфракны тигезли иде.

– Тимер ярдәмчең уңган икән. Кыйммәттер, бабай? – Сүз юктан сүз, аны роботның бәясе бөтенләй кызыксындырмый иде.

– Малайлар ясап кайтарды. Әти, сиңа бүләк, диләр, рәхмәт яугырлары.

«Минем кадерле ата икәнемне бел!» – дигәндәй, карт горур гына башын артка чөеп алды.

– Улларың талантлы икән, бабай.

– Әйтмә дә! Калай кисәгеннән дә җанлы рубыйт әтмәллиләр.

Эттән – эт, беттән бет туа, ди татай, үзенең зурлыгын ул эт белән дә үлчи, Рудия күләмендә танылган авиаконструкторларның балалары да, һичшиксез, булдыклыдыр. «Җәннәт почмагы»на менә дигән вәкилләр!

– Оныкларың бармы соң, бабай?

– Икәү, – диде карт. – Ир балалар.

– Авылга кунакка кайталармы?

– Нинди тулык алардан! Мин аларның телен барыбер аңламыйм. – Хәсән бабайның тавышында үпкә сизелде. Фикерен эченә йомды: аксакал язмыш тарафыннан болай да кимсетелгән, аның нәсел дәвамы чит кавем кочагында эрегән иде. Ул күңелсез генә карт белән саубуллашты. Клубта директор мәдәни чаралар турында белешмә яза иде, кәгазеннән аерылмыйча гына:

– Илдус күгәрченем, бүген без нинди кичә уздырдык әле? – диде.

Егет аптырап җилкәсен җыерды. Көн кичкә авышкан, тиздән кояш байый иде.

– И–и, миңгерәмә инде, Илдус күгәрченем! Фактта узмады, ә кәгазьдә узды! Миннән мәдәният бүлеге җитәкчесе отчет таләп итә. Давай, давай, фантазияңне эшкә җик! Кичәнең исеме ничек? «Җырлы-биюле гомер»ме? «Такмаклар ярышы»мы? Әллә «Авыл көйләре»ме?

Мирзамны салкын тир бәрде. Хатын аны ялган буявына мана, хәер, ул үзе дә Илдус исемле кырыгалдар иде. Тик аны акларга була: егет татай халкы ирекле һәм бәйсез дәүләттә яшәсен өчен битлек кияргә мәҗбүр иде.

– Белешмәне бирсекөнгә илтерсез, иртәгә дискотека оештырабыз, – диде Мирзам.

– «Без» дигәнең кемнәр инде ул, күгәрченем?

– Яшь парлар – Ильяс белән Мәрьям булышабыз, диләр.

Директорның йөзе чалшайды.

– Аһ, төлкеләр! Сиңа да койрык болгадылармы? Тыгылмаган җирләре юк! Шулар гына «клуб йозакта» дип безнең өстән жалу сырлыйлар.

Егет:

– Ата-баба туфрагы тартадыр, аларны читкә какмыйк, – дип, яшьләрне якламакчы иде, Фәзилә аны да бәреп атты:

– Күгәрченем, син хет белмәгән башың белән лыгырдама! Дүрт ел элек ике әрсез, вокзалда танышкан Зөлфиягә ияреп, Сыерга кайтты да, айлар буе мәрхүмә Фазыйлә әбинең бәлеш-коймаклары белән сыйланып ятты. Шуннан бирле Сыерга ияләште, төлкеләр! Яр буенда рәхәтләнеп аунылар. Ашау – байдан, үлем – Ходайдан дигәндәй, авыл юмарт бит, кемнәрдәндер сөт-коймак, кемнәрдәндер йомырка теләнәләр. Акча Мирзамның да оядагы мая яңашәсенә салырга җыенган хыял чатнап ватылды.

– Татайча сөйләшмиләрмени?

– Юк, гел инглизчә. Пачпыртлары да чит илнеке. Киленнәр Әмрикән, оныклар да шундагы мәптектә укыды. Олысы Энри атлы, кечесе – Мельс, икесе дә – кусмик караб төзүче. Чү, син үзең кем әле? Моңарчы Сыерда күзгә-башка чалынмадың.

– Илдус мин, бабай. Клуб хезмәткәре. – Мирзам алдашырга остарды шикелле, тотлыкмый башлады. – Базыңда җәйлеккә ашарга бәрәңге каламы?

– Кала, кала. Килеп ал! Пычрак димә, мин «җир алмасы»н яңгыр яугач казытам рубыттан, бакча чиләнгәч. Аннан балчыгы белән киптерәм, ул шулай яхшы саклана, череми, – дип мактанган юмарт картның бәхете бәрәңге белән чикләнгән, аның ни уллары, ни оныклары чын татай түгел иде. Тик егет бу яньчегенә күпме экономия! Әле балык тотып саталар үзебезгә үк, үзебезнең елгадан, адәм ыстырамы!

Хатын шытыр-шытыр язды да, каләмен өстәлгә ыргытып:

– Шәп! Отчетыма сукыр чебен генә абынып егылыр, – диде. – Нәрсә уңайсызланасың, күгәрченем? Алдашу – зур гөнаһ дип, вәгазь укы тагы! Гел дөресен генә сөйләгән кешене табып китер, давай! Өстәге түрәләр көн саен күзгә төтен өрдерә. Алар белән чагыштырганда, без – фәрештә!

«Мине Җиргә чүп җыярга җибәрмәделәр, миңа олы миссия йөкләнде», – дип, Мирзам үзен тынычландырса да, ялганнан тын кысыла иде. Ул тынчу бүлмәдә һава җитмәгәндәй еш-еш сулады. Таза гәүдәле Фәзилә аны ишеккә табан кысрыклады.

– Әйдә, егетләр-кызлар белән танышасыңмы?

Таныша, әлбәттә, таныша! Сыер авылының киләчәге – яшьләр арасыннан килеш-килбәте, акыл-зиһене, уй-нияте белән сокландырган пар сайлангач та, ул әзерлек эшләренә керешер...

Сәхнә чуар, кайсы кырын ауган, кайсы чүмәшкән, кайсы утырган иде, директор белән Мирзамны күргәч, халык җанланды, солдатлар кебек бер сафка тезелде.

– Ардыгызмы, бәгырь кисәкләрем? – диде Фәзилә. – Моннан соң күрше авылга йөрмисез. Менә безгә яңа җитәкче билгеләделәр. Кул чабып сәламләгез әле!

Егетнең күзе маңгаена менде. Нәрсә бу, нәрсә?! Болар бит... болар әби-бабайлар! Ул качарга җыенгандай артка чигенгән иде, директор тагын гәүдәсе белән кысрыклап, колакка «өрде»:

– Авыл картайды, күгәрченем, димәк, бәлеш төбе катты. Ни бары белән сыйлан инде, яме! Әгәр дә ки, без беренче урынны яуласак, сиңа ике йөз тәңкә премия яздырттырырмын, Алла кушса. Җырлат, давай!

Житез «артист» карчыклар Мирзамны уратып та алды.

– И балакаем, безнең хуҗабызмыни инде син? Төкле аягың белән!

– Ай, бигрәк ябык! Шыр сөяк!

– Ничава, без аны симертербез, – диешә әбиләр. Ир-ат җенесе «хуҗа» дип китеп егылмады, танышу кәмитен читтән генә күзәтте.

Егет кулын шапылдатты:

– Рәхмәт, рәхмәт! Ике соравыма җавап бирерсезме икән, җәмәгать? Нишләп әле сез күмәкләшеп җырларга уйладыгыз?

Бабай халкы пеләш башлы картны «арадашчы» итеп, алга чыгарды:

– Фәйзетдин, синең телеңә шайтан төкергән, сөйлә!

«Пеләш» кәкре таягын әле бер, әле икенче кулына күчерде. Аннан соң тамагына сөяк кадалгандай озак кына йөткерде.

– Ә сез – куркакларга кем төкерде икән? Хагын-нахагын сөйләсәк – «кара козгын» апкитә дип дер калтырыйсыз. Кхым, кхым... Безнең авылда мең шәхси хуҗалык иде, энем, кем Илдус. Калхуз алдынгы иде, сөт белән уңдык без, һәр сыерның маңгаена орден чәпәрлек иде. Мин ферма мөдире идем ул чакта. Халык эшле-ашлы иде. Җитмәгәнен кыр-басудан чәлдердек. Бала-чага мәптеккә сыймый, һәр йортта бишәр-алтышар олан иде. Берзаман карак керде авылга, энем Илдус.

Ахыры бар >

АТНА САЕН БЕР БҮЛӘК

ЯЗЫЛ!
2024 елның беренче яртыеллыгына
«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»
газетасына язып

П2435 >>
571 сум 98 тиен
(җомга)

П2409 >>
1255 сум 86 тиен
(сиш., чәрш., җомга)

КВИТАНЦИЯНЕ БЕЗГӘ ҖИБӘР!
89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт

БҮЛӘК ОТ!
Атна саен бер приз иясе ачыклана.
9 ноябрьдә уйнатылачак бүләк –
КУКМАРА БАШМАГЫ

Бу атна җиңүчесе – Саба районы Кече Кибәче авылында яшәүче Мифтахова Хәлимә. Котлыйбыз һәм элемтәгә чыгуыгызны үтенәбез!

ҖИҢҮЧЕ БУЛ!

Акциядә катнашучыларны гыйнвар аенда тагын да зуррак бүләкләр көтә

ТУЗАН СУЫРТКЫЧ
КЫСКА ДУЛКЫНЛЫ МИЧ
ИТТАРТКЫЧ
МУЛЬТИПЕКАРЬ
ҮТҮК

Тулырак сайтта: vatantat.ru
Акция 2023 елның 29 сентябреннән башлап 2024 елның 10 февраленә кадәр дәвам итәчәк.
Акцияне оештыручы – ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

Реклама 16+

Әз-мәз мәзәк

– Каян шул хәтле күп дошман җыярга өлгердең?
– Аралашучан мин.

***

Берәр яхшы егет белән очрашып йөри башласаң, иптәш кызың шундук психолог, психиатр, адвокат һәм детективка әйләнәчәк.

***

– Нәрсә ул инфляция?
– «Бар да 36 сум» дигән кибеттә 200 сумнан да арзанрак әйбер таба алмау.

***

– Хөрмәтле әти-әниләр! Бүген бушлай ашау өчен акча җыешабыз.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: сахра, Кабан, гаурәт, хаста, Лир, әнә, Аятел, ян, кысыр, сугыш, басым, кат, анар, Крылов, фа, иза, Тимершәех, ал, Янин, нам, Сталин, фон, тыш, Яуширмә, скат, сибс.

Вертикаль: сәхәр, балта, СТС, Ан, яран, ястык, Хөсәен, Сарман, аша, сыр, ага, ум, Франция, каш, Нух, Кулаткы, Ария, ышкы, ис, бәртәс, Алихан, фри, ат, тоз, лакомб, Флюра, вак, Нәс.

Газетаның киләсе саны 8 ноябрьдә чыга.



Беләсең килсә...

1 Россиядә Президент сайлау ничә ел саен үткәрелә?
а) 4;
б) 5;
в) 6.

2 Петрикор нәрсә ул?
а) тырнак кисү өчен махсус кайчы;
б) яңгырдан соң чыккан тәмле ис;
в) машина тәгәрмәчләрен турайту җайланмасы.

3 Мөдәррис Әгъләмов СССР Язучылар берлегенә ничәнче елда кергән?
а) 1973;
б) 1975;
в) 1978.

4 Бу язучы Воронежда туган:
а) Иван Бунин;
б) Самуил Маршак;
в) Федор Тютчев.

Җаваплар: 1. в); 2. б); 3. а); 4. в).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 13584 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 349

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кулъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+